www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 47 (1463) 1 декабрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga


5

60 елдан артык гомерен тюркология фәненә багышлаган, татар дөньясында күренекле филология фәннәре докторы, милли фольклор өлкәсендә алыштыргысыз галим булып танылган Марсель ага Бакировка 90 яшь тула.

6

Әти-бабаларының чыгышы буенча Балтач районының Чапшар авылыннан булган һәм тора-бара Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты дәрҗәсенә ирешкән күренекле җырчы Альберт Әсәдуллинга 75 яшь тулды.

12-13

Исламия Мәхмүтова 19 яшендә Тинчурин исемендәге драма театры сәхнәсенә килә һәм тора-бара, бернинди указларсыз гына коллективта да, халык арасында да «Күчмә театрның әнкәсе» дигән дәрәҗәле исемгә лаек була.

«Син бит минем бергенәм», – дип, сөеп Яшәде ул шанлы сәхнәне!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россиядә 2024 ел – «Гаилә елы» дип игълан ителде.
- Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары раславынча, Россиядә еллык инфляция 7,4 процентка кадәр тизләшкән.
- Депутатлар 2024 елга һәм 2025-2026 еллар планлы чорына Татарстан бюджеты турында закон проектын кабул итте.
- Мәскәү өлкәсендә Волков мөселман зиратында халык артисты Ренат Ибраһимовка мемориал һәйкәл ачылды.
- Татар федераль милли-мәдәни автономиясе «Нәни шәкерт» дип аталган язу дәфтәре чыгарып, Россиянең татарлар яши торган регионнарына таратты.
- Казанда «Дала Евразиясе халыклары тарихы һәм мәдәниятенең актуаль проблемалары» исемле халыкара түгәрәк өстәл утырышы узды.
- Казан Россиянең иң югары тормыш сыйфаты булган топ-10 шәһәре исемлегенә керде.
- Камилә Вәлиева Мәскәүдә фигуралы шуу буенча Россия Гран-При бәйгесенең алтынчы этабында җиңү яулады.
- Әгерҗедә туып-үскән Ислам Гаврилов «Зур тәнәфес» Бөтенроссия бәйгесендә җиңү яулап, 1 миллион сумга ия булды.
- Мөслим районында III Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивале узды.
- Мәскәүнең Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә оештырылган «Россия» күргәзмәсендә Татарстан Республикасының Яңа ел чыршысы ачылды.
- Самара шәһәренең Җәмигъ мәчетендә татар теле дәресләре башланды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

1 декабрь – график, нәкышче, педагог Җәгъфәр Гыйззәт улы Булатның тууына 120 ел (1903-1981);

– актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Исламия Һидиятулла кызы Мәхмүтованың тууына 80 ел (1943–2019).

3 декабрь – рәссам, график, ТАССРның халык рәссамы һәм атказанган сәнгать эшлеклесе Гайшә Габдрахман кызы Рахманкулованың тууына 110 ел (1913-1991).

4 декабрь – актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Елена Ефимовна Ненашевага 60 яшь (1963).

6 декабрь – актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Раушания Самат кызы Фәйзуллинага 60 яшь (1963).

СЫНАМЫШЛАР

1 декабрьдә һава торышы нинди булса, кыш буена шундый була ● 3 декабрьдә кар яуса, 3 июньдә дә яварга мөмкин ● 5 декабрьдән чана юлы төшә ● 6 декабрьдә җил төньяктан иссә һәм кар яуса, 6 июньдә яңгыр ява ● Төнлә ай кызарган кебек булса, иртән җил көчәя һәм кар ява ● Кар явар алдыннан йолдызлар бик кечкенә булып күренә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 49 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 18 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 29 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **16 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **8 декабрьдә 7 сәгать 13 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Декабрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 3 декабрь.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр (27 ноябрь – 5 декабрь) организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел әүвәл аеның 18 нче көне

КӨН КАДАГЫ

Иршад ГАФАРОВ

МӘКЕРДӘН ТУГАН ГАУГА...

Күптән түгел Үзәк банк 1000 һәм 5000 сумлык акчаларның яңа бизәлеше турында белдерде. Бер меңлек акчаның икенче ягында Сөембикә манарасы һәм аның янәшәсендә чиркәү бинасы сурәтләнгән. Кемнәргәдер манарадагы ярымай хуш килмәгән, ә икенчеләрдә чиркәүнең гөмбәзендә хач булмау тынгысызлык тудырган. Бездә андый адәмнәрне «Йомыркадан җөй эзләүче» дип атыйлар. Татарстанда төрле диннәрнең, милләтләрнең дус-тату яшәве андыйларның эчен пошыра. Бу турыда үзәк һәм җирле телевидение каналларында фаразлар яңгырады. Инде Үзәк банк андый меңлек купюралар чыгаруны туктаткан, бәлки киләчәктә, «җитешсезлекләрне төзәткәннән соң» чыгарыла башлавы мөмкин, дигән фикерләр дә ишетелде. Димәк, кыйммәтле кәгазь, буяуларга тотылган миллионлаган сумнар көлгә әйләнеп юкка чыккан була. Ә шул ук чакта авыру балаларга матди ярдәм сораган белдерүләр экраннардан көн саен дистәләрчә тапкыр яңгыраудан туктамый.

Безнекеләр бу манзарада катнашыбыз юк, аны Түбән Новгород рәсемчеләре татарстанлылар белән килешмичә ясаган, ә алар чынбарлык турында белми, дип акланырга тырышты. Икенчеләре Кол Шәриф мәчетен һәм Благовище чиркәвен ясарга кирәк булган, дигән фикерне дә әйтә. Хәттә, монда үзәкнең дә гаебе бар, дигән сүзләр ишетелде. Чыннан да, кайбер «акыллы» башлар, песи эшен тәмамлагач калдыгын яшерергә теләгән кебек, татарның чын тарихын күрсәтмәскә яки аны бозып күрсәтергә маташа.

Ни кызганыч, бу бина бит элек чиркәү булмаган, дигән сүз дә ишетелмәде. Чынлыкта рәссамнар дөрес булып чыга. Алар бит хәзерге вакытта булган мизгелне сурәтләгән. Казан урыслар тарафыннан яулап алынгач, шәһәрдә шул чордагы барлык архитектура һәйкәлләре юкка чыгарылган, дигән фараз яшәде. Бу дөреслеккә туры килми. Елъязмачы болай дип яза: «...царь, смотряши стенные высоты и мест преступных и, увидев, удивился необычной красоте крепости града» (укучыларга автор сүзләрен тәрҗемәсез бирергә булдык. Фехнер М. «Великие Булгары. Казань. Свияжск). Димәк Явыз Иван әлеге һәйкәлләрне үзе дә күргән булып чыга.

Яңа чыганаклардан күренгәнчә, барча тарихи һәйкәлләр дә юкка чыкмаган. Шәһәрнең юбилее уңаеннан «Святозарная Казань» исемле хезмәт дөнья күргән иде (Санкт-Петербург, 2005). 173-175 битләрдәге 287, 289, 290 саннардагы гравюраларда без Сөембикә манарасын һәм аның янәшәсендә мәчет хәрабәләрен күрәбез. Ә 291 нчесендә Казан Кремле хәзерге Яшьләр үзәге ягыннан сурәтләнгән. Алар рәссам Э.Т.Турнерелли тарафыннан ясалган. Бу рәсемнәрдән, әлеге «сарай чиркәве» дип аталган бинаның элек замандагы тоткан урынын



билгеләп була. Ул урыслар тарафыннан төзелмәгән, ә Казан дәүләтчелеге вакытыннан калган «Нурали» (Нур Али Ширин – кенәз, вәзир) мәчете җимерелергә булырга тиеш, чөнки аның баскычлары, архитектурасы хәзергедән бары гөмбәзе белән генә аерыла. Заманында ул Кремльдә урнашкан хезмәткәрләр өчен ашханә булып хезмәт итте. Автор, мәгариф министры урынбасары вазыйфасын башкарганда, озак еллар аның баскычларыннан төшке ашка күтәрелде. Соңыннан, губернатор сарае төзелгәч, галиҗанәпләр өчен аны ябык коридор белән тоташтырып, бинага гөмбәз өстәп, хаҗ куеп чиркәүгә әйләндерә. Э.Т.Турнерелли әлеге гравюраларны 1840 нчы елларда ясаган. Әгәр чиркәүне урыслар төзегән булса, православие дине чәчәк аткан чорда, Кремль үзәгендә гөмбәзсез, хачсыз ярым җимерек чиркәү бинасы торуына берничек тә ышанып булмый. Шул ук вакытта, гравюрада берничә православие храмын да күрәбез.

Бер уңайдан Сөембикә манарасы кайчан һәм кем тарафыннан төзелү турында да бәхәс баруына тукталыйк. Укучылар игътибарына 1877 елның 2 июлендә «Губернские ведомости» газетасында басылган мәкаләне тәкъдим итәбез. Аның авторы протоиерей Пл. Заринский. Әлеге газетаның берничә санында «Борынгы Казан турында язмалар» дөнья күрә. Ул А.Курбскийның сүзләренә таянып (авторның стиле сакланды) «...потекоком ко городским стенам и к той великой башне, яже пред враты стояла на горе...» – дип яза. Бу шулай ук Борынгы Казанда, хәзер Сөембикә манарасы торган урында, нииндидер бөек манара торганын раслый. Сүзен дәвам итеп ул: «...Сөембикә исемен йөртүче әлеге манараның төзелеше үзгәргән булырга мөмкин, шул ук вакытта аның нииндидер мәчеткә караган булуы бәхәссез. Беренче карашта ук сез аның астагы дүрт катының, һичшиксез, борын заманда ук төзелгән булуын һәм башкаларыннан аерылып торуын күрерсез». Безнең карашка, шул чорда беркем дә урыс дин әһеленнән татарларның дөрес тарихы турында мәкалә язарга таләп иткәндер дип әйтә алмыйбыз.

Тагын бер мизгелгә игътибар итәсебез килә. «Татарстан АССР тарихы турындагы мәгълүматлар... 1565-1568 һәм 1646 еллар» (Ленинград: изд. Академии наук, 1932.) дигән хезмәтнең кушымтасында Казан шәһәренең XVI-XVII гасырлардагы планы бирелгән. Аннан күренгәнчә, Казан Кремлендә хәзерге Сөембикә манарасы янында алты «татар сарае» булган. Аның беренчесе хәзерге Президент сараена туры килә, бишенчесе – Сөембикә манарасы, алтынчысы чиркәү бинасы (Нурали мәчете).

Әгәр манара урыслар Казанны алгач төзелгән булса, урынлы сорау туа, аның бит сызымнары сакланмаса да, мастерларның яки төзүчеләрнең исемнәре сакланып иде. Казан кирмәнен төзекләндерүчеләрнең исемнәре билгеле бит. Чөнки Явыз Иван шәһәрнең диварларын таштан коруны Постник Яковлевка тапшыра, ә аның буйсындырылган Казанның һәйкәлләрен үз күзе белән күрү мөмкинлеге була. М.Худяков язганча: «...алай гына да түгел, Кол Шәриф мәчетен күрү, аның уенда урыс һәм дөньяның булачак төзелеш сәнгатенең җәүһәре – Василий Блаженныйның сурәте пәйда була». Дөрестән дә, күпләр әлеге чиркәүнең гадәти булмаган формасында татар мәчетләренең төз манараларын шәйли.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Фактлар теле күпне сөйли

Ноябрь ае ишарәле вакыйгаларга бай булды. Төп геосәяси вакыйгалар Украина һәм Якын Көнчыгыштагы хәлләр белән бәйле рәвештә куерды. Шул ук вакытта, гаммәви мәгълүмат чараларында яктыртылуы ягыннан, соңгысы беренчесен әүвәл күләгәдәрәк тә калдыра башлаган иде. Ә озак еллар геосәяси тотрыксызлык үзәге булып хезмәт иткән ул төбәктә сугышның янә яңартылуына 7 октябрьдә ХАМАС хәрәкәтенең Израиль территориясен Газзә секторы ягыннан тупланышлы ракета утына тотуы, коралы төркемнәрнең чик буе районнарына да үтеп керүе һәм анда тыныч халыкка каршы вәхшиләрчә җинаятьләр кылып, күп кешене (шул исәптән хатын-кыз һәм балаларны да) тотыклыкка алып китүе рәвешендә кылган зур хәрби провокация сәбәпче булды. Бу исә Израильгә, илне сугыш халәтенә күчереп, Газзә секторында ХАМАС хәрәкәтенә каршы җир өсте операциясе үткәрү мөмкинлеге бирде.

Мондый борылыш дөньяда болай да киеренкелек чигенә җиткән геосәяси вазгыятьнең тагын да кискенләшүенә, халыкара хокук нормаларының тәмам җимерелүенә, ә глобаль бүленешкә инде дөнья тотучылар планын тулырак чагылдыра торган яңа төсмерләр өстәлүенә дә китерде. Әммә, хокук нормалары өстенлек иткән дөньяда андый очракларда, барлык халыкара хокук механизмнары һәм аларның көч структуралары да эшкә җигелеп, әлеге провокациянең башкаручылары гына түгел, ә аның оештыручылары да ачыкланырга, кулга алынырга һәм халыкара суд каршына бастырылырга тиеш иде кебек. Тик алар бүген инде эшләми. Охшаш хәлләр исә БМО мисалында да бик ачык күренә.

Мәгълүм ки, БМО Куркынычсызлык Шурасы (КШ) Якын Көнчыгыш буенча Бразилия әзерләгән резолюция проектын да, соңрак Россия әзерләгәнен дә кабул итмәде (чөнки АКШ һәм Бөекбритания вето хокукын кулланды). Ә Россия һәм Кытай инде АКШ әзерләгән проектка да вето салды. Нәтиҗәдә, гарәп илләре исеменнән Иордания керткән һәм низаг зонасында кичекмәстән тынычлык урнаштырырга чакырган резолюция проекты гына 27 октябрьдә БМО Генераль Ассамблеясендә (ГА) 120 тавыш белән кабул ителде. Әмма анда ХАМАС хәрәкәтен террорчылыкта яки явыз провокация кылуда гаепләгән пункт юк. Өстәвенә, БМО КШ карарларыннан аермалы буларак, БМО ГА резолюцияләре үтәү өчен мәҗбүри түгел. Шуңа да карамастан, бу очракта төрле илләрнең ул резолюциягә реакциясе төрлечә булды. Әйтик, Австрия, АКШ, Венгрия, Чехия һ.б. илләр аңа каршы. Израиль исә, андый резолюциядән соң, БМОның бер генә грамм да легитимлыгы калмады, дип белдерде. Ә проектны хуп күргән дәүләтләр арасында, гарәпләрдән тыш, Кытай, Россия, Төркия кебекләре дә бар. Документтан ХАМАС хәрәкәте дә канәгать калды. Шулай итеп, дөньяда бүленеш Израильгә карата мөнәсәбәт буенча да формалашты. Ә Төркия президенты Р.Эрдоган Газзәдәге хәлләрне «тәре һәм ярымай сугышы» дип атады һәм анда Көнбатышны гаепләде. Соңрак Анкара Израильне «террорчыл дәүләт» дип тә атады һәм, премьер-министр Биньямин Нетаньяхуны геноцидта гаепләп, Халыкара җинаять суды каравына бирде. БМО КШ исә низаг зонасында гуманитар паузалар ясау турында гына резолюция кабул итә алды.

Бүгенге хәтәр геосәясәттәге төп сорауны куйыйк: Якын Көнчыгышта яңартылган сугышның Украинадагы хәлләргә ни катнашы бар? Тик, бар икән шул! Дөрес, бүген гаммәви мәгълүмат чараларында бара торган «мәгълүмат һәм ялган сугышы» чорында төп сорауга җавап табуы бик җиңел түгел. Ә сәясәттә эшнең асылын аңлау өчен, кайбер конспирологик теорияләргә дә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Җәмгыятьтә андый теорияләргә кытлык юк һәм аларга караш бертөрле генә түгел. Ә киң җәмәгатьчелек игътибарына андый тәгълимат һәм алар белән бәйле «серле» оешмалар хакындагы мәгълүмат, гадәттә, актуальлеге узгач кына чыгарыла. Әйтик, күптән түгел үзәк телевидениенең «Беренче канал»ында үзе дә шактый ук «серле» ханым М.Бутина алып бара торган «Куклы наследника Тутти» тапшыруының берсе тулысынча «Бильдерберг клубы»на багышланды (анда мәгълүм геосәясәтче Г.Киссинджер һ.б. турында әйтелде, хәтта «Комитет 300», «Рим клубы» кебек оешмалар да телгә алынды). Әлбәттә, андый тапшыруларның сәяси вә психологик максатлары яхшы аңлашыла.

Мәгәр, «серле теорияләр»нең рәсми каналлар әлегә читләтебрәк уза торганнары да бар. Бу җәһәттән игътибарны «күкләр сәясәте» («небополитика») дип йөртелә торган экспертлар, бигрәк тә Андрей Девятов атлысының (СССР чорында – Баш разведка идарәсе полковнигы, Кытай буенча белгеч, Үсеш белән идарә итү академиясе – Күкләр сәясәте институты әһеле) карашлары җәлеп итә. Моннан 3-4 ел элек ул бүген бара торган кискен үзгәрешләрне дөнья тотучыларның (Девятов аларны «планлаштыручы» дип атый) «Соломон планы»н гамәлгә ашыруы белән аңлаткан иде. Искәртеп үтик, Соломон патша (Коръәндә – Сөләйман пәйгамбәр) – б.э.к. якынча 1012-972 елларда Израильдә хакимлек иткән Давид патшаның (Коръәндә – Давыт пәйгамбәр) улы. Википедия буенча, Соломон патша үзе Израильдә б.э.к. якынча 972-932 елларда идарә иткән.А.Девятов язуынча, яһүдләрнең киләчәген кайгыртып һәм борынгы Мисыр мистерияләренең бай тәҗрибәсенә таянып, ул үз халкының тыныч юл белән дөнья хакимлегенә ирешү планын кора. Ошбу стратегик план 3000 елга исәп тотып төзелә.

(Ахыры 23 нче биттә)

Чыршыларның берәмләп сату бәясе

Татарстанда чын чыршылар озынлыгына карап 550 сумнан 4,5 мең сумга кадәр тора. Әлеге бәяләр эшмәкәрләргә ваклап сатып алганда гамәлдә. Алга таба эшмәкәрләр үз бәяләрен билгеләячәк. Бу хакта Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының эш нәтиҗәләренә багышланган матбугат конференциясендә республиканың урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров хәбәр итте.

Шулай итеп, 1 метрга кадәрге озынлыктагы чыршы 550 сумга төшәчәк. Әгәр агачның озынлыгы 2,1-3 метр булса, ул 1,1 мең сум торачак. Ә 7,1-11 метрлы чыршыларны 4,5 мең сумга сатачаклар.

Спикер сүзләренчә, 2023 елның 10 аенда республикада аукционнар нәтиҗәсендә 223,7 мең кубометр агач сатканнар, ул барлыгы 50,8 млн сум булган.

tatar-inform.tatar

1 нче биттә – Татарстанның халык артисты Исламия Мәхмүтова.

Шагыйрь кичәсе



Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинның 75 еллыгына багышланган искә алу кичәсе булып узды. Әүвәл тамашачыларны сәхнәдән шагыйрьнең хатыны Клара ханым сәламләде. Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Роберт Мөгаллим улы берничә чакырылыш депутат булганда бергә эшләгән елларны искә алып үтте.

Р.Миңнуллинның истәлеген мәңгеләштерү өчен җөмһүриятебездә байтак чаралар узды. Мәсәлән, республика балалар һәм яшүсмерләр китапханәсенә шагыйрь исеме бирелде. 2021 елда беренче тапкыр балалар һәм яшүсмерләр әсәрләренә Р.Миңнуллин исемендәге әдәби конкурс үткәрелгән иде. Быел ул тагын оештырылды. Әдәби бәйгене Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге үткәрде. Җиңүчеләрне кичәдә мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин тәбрикләде. Драма әсәрләре номинациясендә Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлүсә Батталова, Әлфис Гаязов пьесалары җиңгән. Дилә Гыйльметдинова, Сәлимә Әскарова белән Елизавета Буланкина һәм Азалия Ибраһимованың иҗат эшләре комикс, әгъни сюжетлы иллюстрация белән «сөйләнгән» хикәя төрендә иң яхшы дип табылган. Иң шәп проза әсәрләрен Ләлә Гыймадиева, Лилия Сираева һәм Галимҗан Гыйльманов тәкъдим иткән. Конкурс нәтиҗәләре буенча балалар өчен иң шәп шигырь шәлкемнәре иҗат итүчеләр – Гөлназ Хәйруллина, Илдус Диндаров, Ленар Шәех. Бәйгегә барлыгы 135 иҗат эше тәкъдим ителгән. Бәйгене алга таба да ике елга бер тапкыр үткәреп бару ниятләнелә.

Иҗат кичәсендә драма театры артистлары башкаруындагы шигырьләр җырлар белән үрелеп барды. Җырчылар В.Ганиева, И.Мөхетдинов, Р.Фасыйхов, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Ф.Каһиров, И.Миранов һ.б. Роберт Миңнуллинның туып үскән төбәккә, авылга, әниләргә, кешегә карата мәхәббәт белән сугарылган садә җырларын хәтердә яңартты. Шагыйрьнең әсәрләрен олысы-кечесе бердәй ярата. Халык язмышы, туган тел, милли тормыш өчен борчылып язылган шигырьләрен кичәдә экраннан Мәдәният министры Ирада Әюпова, Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, шагыйрь Рәдиф Гаташ, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Айгиз Баймөхәммәтов укып ирештерде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Тел куллану тарая

Россиядә яшәүче халыкларның телләрен саклауга юнәлдерелгән федераль программалар булмау сәбәпле, татарлар күп яши торган җирләрдә татар телен куллану катлауланган. Бу хакта Татарстанда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме утырышында ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсәдуллина хәбәр итте:

«Туган телләрне өйрәнү өлкәсендә федераль мәгариф законнарының үзгәрүе нәтиҗәсендә яңа методик кулланмалар, яңа дәреслекләр эшләү мәсьәләсе актуаль булып кала. Туган телне белү өчен укучыларның мотивациясе кимү тенденциясе дә бар».

Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы белем сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән җиде дәүләт программасында катнаша. Бүген программаларны үзләштерү 89 миллионнан артык сумны тәшкил итә. Мәгариф һәм фән министрлыгына караган 70 чараның 40ы 58 миллион сумга финансланган.

А.Әсәдуллина Татарстанда яшәүче җирле халыкларны саклауга зур игътибар бирелүен дә билгеләп үтте. «Мәсәлән, элек эшләрне татар телендә генә кабул иткән бәйгеләргә чуваш, удмурт, мари, мордва телләрендә дә номинацияләр өстәлде», – диде ул.

ТР Премьер-министр урынбасары, Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев Россия субъектларында яшәүче татар теле укытучылары ассоциациясе төзелүен дә искә алды. «Россия субъектларында татар теле укытучыларына ярдәм итү өчен Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы Туган тел укытучылары ассоциациясе төзеде. Без закон, программа кабул ителгәнен көтеп утырмыйбыз, алга барабыз. Туган тел укытучылары форумында бу мәсьәләне чишү юлларын эзләдек», – диде В.Шәйхразиев.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА.

Шәриф Камал кайта

● Шәриф Камал булып киенгән артист Булат Зиннәтуллин.

«Шәхесләребез» сериясендә тагын бер күренекле әдибебез – язучы, драматург һәм журналист Шәриф Камалга багышланган фәнни-популяр басма дөнья күрде. Ш.Камал турында беренче тапкыр язылган бу монографик җыентык «Татнефть» компаниясенең Хәйрия фонды ярдәме белән «Җыен» фонды тарафыннан бастырылган. Китап җәмәгатьчелеккә тантаналы рәвештә Татар китабы йортында тәкъдим ителде.

Китапны әзерләү ике ел элек башланган. Татар әдәбияты тарихы музее һәм Ш.Камалның мемориаль фатиры директоры Айдар Шәйхин язучыга бәйле өйрәнелмәгән документларга, хатларга, материалларга игътибар итә. Җитәкче күңелендә Ш.Камалга багышланган фәнни-популяр җыентык әзерләү уе ныгый, ул бу хакта Халык шагыйре Разил Вәлиев белән дә киңәшә. Ул исә бу фикерне хуплап каршылый, «Җыен» фондының «Шәхесләребез» сериясендә чыгара торган китаплар өчен җаваплы Фоат Рафиков та үз фатихасын бирә.

Китапны әзерләү эше кузгала, әмма Татарстан Милли музеенда, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Мирасханәсендә, Дәүләт архивында, язучының туганнарында, Ш.Камал музей-фатирының үзендә саклап килгән барлык материаллар да гарәп имлясында, аларны кирилл хәрефләренә күчерергә кирәк. Директор А.Шәйхинның һәм өлкән фәнни хезмәткәр Гөлназ Җиһангированың көнне төнгә ялгаган хезмәте башланып китә, кульязмаларны барлап, укыйлар, кирилл хәрефләренә күчерәләр.

Милли музейның фәнни-тикшерену эшләре буенча директор урынбасары Светлана Измайлова искәрткәнчә, язучының кызы Зәйнәп Байгилдиева әтисенең мирасын саклап калмаган булса, бу китап та тумаган булыр иде. Ул берничә ел дәвамында әтисенең шәхси әйберләрен музейга тапшырган. «Милли музей гаять зур чыганакларны саклап килде. Көндәлек язмалар, кульязмаларның күчермәләре, караламалар, хатлар – гаҗәеп зур хәзинә. Бу – әдәбият һәм мәдәният хәзинәсе, ул хәзер безгә бик кызыклы», – диде ул.

Китапның фәнни концепциясен эшләүче, кереш мәкалә авторы, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина да «Шәхесләребез» сериясенең моңа кадәр күләгәдә кала килгән исемнәрне кайтаруга әһәмиятле өлеш кертүен билгеләп үтте, шул ук вакытта Ш.Камалның беркайчан да татар халкы мәдәни тарихыннан китеп тормавын искәртте. Язучы Совет хакимлеге елларында мәктәптә дә, югары уку йортында да совет әдәбиятына нигез салучы төп прозаик буларак өйрәнелде. Әмма 1986 елдан соң башланган үзгәртеп корулардан соң совет әдәбияты кисеп калдырылды. «Ләкин шул вакытта да Ш.Камал исеме татар әдәбияты тарихыннан китмәде, аның иҗаты өйрәнүдә яңа сулыш ачылды», – диде ул. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәби бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов сүзне XX йөз татар әдәбияты безнең алтын чорыбыз булуын, бу дәвердә дистәләгән шәхес үсеп чыгуын әйтеп башлады. Аларның һәркайсының әдәбият тарихында үз урыны бар. XX йөз башын Г.Тукай, Г.Исхакый исеме белән атасак та, Ш.Камал, Г.Камал Ә.Еники, С.Рәмиев һ.б. бер-берсенә ярдәм итеп, яңа әсәрләренә этәргеч биреп иҗат иткәннәр, шушы чор мохитын тудырганнар. «Бу төркемнән бер-икесен генә алсаң да, XX йөз башы сыеган башлый. Ш.Камалның әдәбиятта яңарыш сыйфатлары Исхакый-Әмирханнарны тулыландыра, алар янәшәсендә Ш.Камал әсәрләрен аларның психологизмына, күңелгә үтеп керә торган сурәт үзенчәлекләренә әсәрләнеп укыйсың. Хәтта жанр сыйфатында да, Шәриф ага новелла жанрының гаҗәеп матур үрнәкләрен биргән шәхес. Аның «Буранда» яки «Чит илдә»се яисә «Акчарлаклар»ы онытылмый», – дип сөйләде Ә.Закирҗанов. Ул яңа китапны да бик кыйммәтле хезмәт, дип бәяләде.

Китапны төзүчеләр – Татар китабы йорты мөдире А.Шәйхин һәм музейның өлкән фәнни хезмәткәре Г.Җиһангирова. Китапта чыккан материаллар исә студентларга, яшь галимнәргә бер юнәлеш, ярдәмлек булыр. Кичә экскурсиядән башланып киткән иде. Экспозиция белән таныштыруны Шәриф Камал «үзе» алып барды! Язучы образында исә Кәрим Тинчурин театры артисты Булат Зиннәтуллин булды.

Чарада галимнәр, әдәбият белгечләре, Казан федераль университет студентлары, Ш.Камалның абыйсы Гыймадиның туруны Ләйлә Шакирова, язучының кызы Зәйнәпнең оныгы Айрат Байгилдиев, Татарстан мәдәният министрлыгыннан бүлек мөдире Айрат Файзрахманов катнашты һ.б. катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Асылташ актриса иде

28 ноябрь көнне 84 нче яшендә Россия Федерациясенең атказанган, Татарстан Республикасының халык артисткасы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Наилә Гәрәева вафат булды.

Наилә Гәрәева – татар театрына 60 елдан артык гомерен багышлаган актриса. Ул 1961 елда В.Качалов исемендәге Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлый һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры труппасына кабул ителә. Н.Гәрәеваның иҗат репертуарында татар, рус, чит ил авторлары әсәрләрендә уйналган 100дән артык образ бар. Иң беренче роле – Хәй Вахитнең «Беренче мәхәббәт» әсәрендә Рәхилә. 1966 елда Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә төп героиня Әсәл образы өчен, актриса 1967 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Н.Гәрәева сәхнәгә тудырган һәр образына үз йөрәгенең бер өлешен, барлык хис-тойгыларын, гаделлеген салып уйный иде, шуңа да аны татар халкы һәрчак гадел әйдәман һәм үрнәк ана сыйфатында кабул итте. Соңгы елларда ул «Бабайлар чуагы»нда – Хәлимә Әмировна, «Әтәч менгән читәнгә»дә – Миңниса, «Исәнме, улым» спектаклендә Ана рольләрен башкарды. Вафаты көнне дә ул Камал театры сәхнәсендә куелучы «Зәңгәр шәл» спектаклендә уйнарга тиеш була.

Н.Гәрәева – тормышта да гүзәл ана, ул халкыбызга талантлы режиссер Фәрит Бикчәнтәевны бүләк итте.

Татар халкының асылташка тиң артисты белән хушлашу 29 ноябрьдә Казан каласының Ш.Мәрҗани исемендәге мәчетендә үткәрелде.

Наилә Гәрәеваның якты образы һәм аның турында әчкерсез истәлекләр күңелләребездә мәңге сакланыр.

«Мәдәни җомга»лылар.

Мәкердән туган гауга...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Наполеон Бонапарт 1812 елда бердә юкка аны «мәчет» дип атамаган. Чөнки ул Мисырны яулап алгач, анда күпләгән көнчыгыш мәчетләрен күргән.

Шулай ук, Постник янында Барма дигән төзүче дә булган, дигән мәгълүмат та сакланган. ТВ-3 каналында (15.03.2013) алып баручы болай белдергән иде: «Барма һәм Постник трактирда храм төзү турында килешкән. Икенче кичтә трактир янында кыйнап, киләчәктә төзү эшләрен булдырмасын өчен, аларны сукырайталар». Билгеле, моның чын булуын расләп булмыйбыз.

Манара элегрәк төзелүне аның архитектурасы да раслый. Әле болгар чорында ук, биналарның аскы өлешендә куб була. Моны әлегә кадәр Русиядә сакланган алар төзегән сарай һәм чиркәүләр дә раслый.

Шулай ук мәскәүлеләр Казан кремлендә мондый манараны нинди максат белән төзегән дигән сорауга да җавап таба алмадык. Миңа заманында мәшһүр галим А.Х.Халиковның чыгышын тыңларга насыйп булды. Ул: «Әлеге манара күзәтү өчен казанлылар тарафыннан төзелгән һәм аңардан Идел агымын 40 чакрымга кадәр күреп була». Мондый манара Бакуда да бар һәм аны «кыз манарасы» дип атыйлар. Урыс телендә «ү» авазы юк, шуңа да аны «кыз» (девичья) манарасы диләр. Сөембикә манарасыннан аермалылыгы шунда, ул төньяктан 28, көньяктан 31метр биеклегендә 8 ярусы таштан корылган цилиндр формасында. 2000 елда манара ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелә.

Әгәр урыслар тарафыннан төзелгән булса, аның атамасы Сөембикә түгел, Маруся яки бүтән, ә аның янәшәсендә Казан ханнарының җәсәдләре җирләнмәгән булса, әбиләр шунда килеп зират кылмас иде. Бу гадәт элек заманнардан ук сакланган бит.

Шулай булгач, нигә инде уйдырма гауга кузгатып, кешеләр күңеленә шом салырга? Заман болай да бик болганчык. Ә Татарстаныбыз бүтән регионнар өчен үрнәк булып тора.

● Кеше туганда, аның баш миендә 14 миллиард күзәнәк була, һәм бу сан гомер буена бүтән артмый. Киресенчә, 25 яшьтән соң көненә 100 әр меңгә кими башлый. 40 яшьтән соң баш миенең деградациясе кисәк тизләнә, 50 дән соң исә нейроннар кибә һәм миның күләме кечерәя.

● Кайвакыт күбәләк, крокодилга кунып, аның тозлы күз яшен эчә, шул рәвешле үзенә кирәк минерал элементлар кытлыгыннан котыла.

● Берләшкән Гарәп Әмирлекләре башкаласы Әбү-Дабида якындагы өч елда оча торган такси пәйда булачак. Американың Archer Aviation компаниясе җитештергән электр машиналарына берьюлы дүрт пассажир һәм пилот сыячак. Гади автомобиль 60-90 минутта үтә торган юлны аэротакси 10-20 минутта узачак, дип фаразлана.

Сокланргыч галим

(Марсель Бакировка 90 яшь)

10 декабрьда исеме бөтен тюркология дөньясында хөрмәт белән телгә алынучы татар галиме Марсель Бакировка 90 яшь тула. Ул фән дөньясына 1960-1970 елларда ук килеп керә һәм шул вакыттан бирле бертуктамый яңа темалар, яңа проблемалар өстендә эшли. Бер-бер артлы саллы-саллы монографияләр чыгара. Ул хезмәтләрнең һәрберсе фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан фәндә яңа сүз, яңа ачыш булып кабул ителә. Галим буларак М.Бакиров үз алдына киң масштаблы, олы максатлар куеп иҗат итә. Аларның берсе – халкыбыз тарихының тирән, әле моңа кадәр ачыкланмыйча калган катламнарына үтеп, рухи байлыгыбыз энҗеләрен табу, аларны халкыбызга кайтару.

Марсель Бакировның фәнгә керткән яңалыклары аның 1972 елда яклаган кандидатлык диссертациясеннән үк башлана. Бу хезмәтне ул төрки һәм татар шигыренең эчке ритмик-интонацион хасиятләрен һәм кануннарын тикшерүгә багышлады, аларны гомумтөрки шигырь төзелешләре белән чагыштырып өйрәнде. Ә андый чагыштыруларны үткәрү өчен галимнән төрки телләрне һәм, беренче чиратта, инглиз телен белү таләп ителә. М.Бакиров җентекләп инглиз телен өйрәнергә кереште, ә бу аңа үзе эшләгән өлкәдә дөнья күләмендәге хезмәтләр, алардагы казанышлар белән танышу мөмкинлеген бирде. Галим төрки шигыренең үзәк проблемаларыннан булган төрки гарузы табигатен эксперименталь-фонетик аппаратлар белән тикшерде, нәтиҗәдә ул төрки шигърияте өлкәсендә үз карашын, үз концепциясен булдыруга ирешә. Әгәр моңа кадәр бу өлкәдә эшләгән И.В.Стеблева, М.К.Хамраев кебек галимнәр, төрки-татар шигъриятенә гаруз системасы ясалма рәвештә кертелгән һәм төрки телнең табигатенә туры килми, дигән караш үткәргән булса, М.Бакиров төрки гаруз – ул төрки шигъриятенең үз казанышлары һәм уңай алшартлары белән гарәп-фарсы гарузы йогынтысы үзара кушылган җирлектә барлыкка килә, дигән яңа караш барлыкка китерде һәм шуны эксперименталь тикшеренүләре белән исбатлап бирде: уртак казанышлар җирлегендә барлыкка килгән төрки гарузның да табигый яңгырашлы булуын, тел үзенчәлекләре белән үрелеп гәүдәләнүен-яшәвен күрсәтте. Бу бөтен тюркология күләмендә яңа караш һәм үзенчәлекле, кызыклы ачыш булып кабул ителде.

1981 елда М.Бакиров Казан университеты нәшриятында «Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» исемле ун табаклык авторлаш хезмәт бастырып чыгарды. Анда ул бәет жанрының генетик тамырларын, аның эволюцион үсеш-үзгәреш баскычларын ачыклады, аларны тематик төркемнәргә аерып, сәнгатьчә эшләнешен-поэтикасын күздән үткәрде. Хезмәт фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды. Гыйльми ачышларны союз күләмендә пропагандалауның Самара шәһәрендә урнашкан гыйльми-зональ үзәге соңыннан әлеге хезмәтне үзенә соратып алдырды һәм аны АКШ, Англия һәм Германия китапханәләренә җибәрде. М.Бакировның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге турындагы мәгълүмат Мәскәүдә «Российские фольклористы» дигән фәнни-библиографик җыентыкта да басылып чыкты.

Фольклорга бәйләнешле тикшеренүләр белән бергә галим шул ук елларда төрки-татар шигыре һәм борынгы төрки поэзиясенә бәйле тикшеренү эшләрен дә алып барды. Үзенең остазы профессор Хатип Госманның хезмәтләрен үзенчә үстереп, ул гомумтөрки поэзиясенең чишмә башын ачыклау һәм иң борынгы жанрлар системасын реконструкцияләү буенча эзләнүләр үткәрде. Шул максаттан, ул Мәскәү, Санкт-Петербург, Алма-Ата, Баку, Ереван, Бишкек, Ташкент, Уфа шәһәрләренең үзәк китапханәләрендә тикшеренүләр алып барды. Шушы эзләнү нәтиҗәсе булып 2001 елда яңа зур саллы хезмәт – «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» дигән монография туды. Аның докторлык диссертациясе дә 1999 елда шушы монографиягә нигезләнеп якланды. Монографиядәге бүлекләрне генә күз алдыннан кичерик: хезмәт – башлангыч поэзиянең материаль нигезе; шигъриятнең фикер һәм сәнгати җирлеге буларак мифология; иң элгәрге шигъри сүз сәнгатенең синкретик табигате һәм морфологиясе; иҗади шәхес күпкырлы һәм күп вазыйфалы сүз остасыннан башлана; язма шигъриятнең иң борынгы үрнәкләре; борынгы төрки поэзиянең тарихи поэтикасы.

Шушы ук хезмәттә «Сак-Сок» образларының килеп чыгуы шәрекъ мифологиясе контекстында тикшерелә. Автор аларны борынгы игезәкләр культына һәм үзе таптан типологик һәм генетик тәңгәлләргә нигезләп, Көнчыгышта эшләнгән борынгы уртак мифология һәм культура мирасына бәйләп аңлата. Бездәге «Сак-Сок»ны борынгыдан килүче уртак катлам җирлегендә туган милли версия итеп карый. Бу сюжетны көньякта Кубрат хан тарафыннан төзелгән Бөек Болгар дәүләтенең аның варислары чорында таркалып юкка чыгу фаҗигасе белән бәйли, ягъни мифологик образларда Кубратның уллары һәм болгар кабиләләре арасында бердәмлек-татулык бозылуның һәлакәткә китерүе чагылыш тапкан, дип карый.

Галим, тюркологиядә беренчеләрдән булып, һун бабаларыбызда һәм борынгы төрки сүз сәнгатендә матур сөйләү-ораторлык сәнгатенең булганлыгын ачты, Орхон язмаларының да шул ук традициягә нигезләнүен исбатлады. Шунысы да әһәмиятле: хезмәттә башлангыч язма сүз үрнәкләре шул чорда төркиләр кулланган иң элгәрге алфавитлар белән бәйләп карала, узган чорларда алар тоткан тәңречелек, будда, манихей, христиан һәм ислам кебек төрле диннәр контекстында тикшерелә. Шушы уңайдан галим әле моңа кадәр фәнни кулланылышта булмаган «Ана һәм угыл» исемле дастан текстын да анализлады.

2019 елда М.Бакиров тагын бер саллы монография – «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» дигән китабын бастырды. Бу хезмәттә дә ул күп кенә галимнәрнең «теше үтмәслек» проблемаларны күтәрә. Мәсәлән, прототөркиләр теленең барлыкка килүе мәсьәләсе. М.Бакиров аны, күптөрле арадаш фәннәрдән, шул исәптән тарих, археология, этнография, мифология, фольклор, тел гыйлеме, диннәр тарихы, философия, антропология һәм, гомумән, күп гасырлык матди һәм культура казанышларыннан киң файдаланып ачыклый.

Бу хезмәт турында азәрбайҗан галиме Тариел Азертюрк болай дип язды: «Профессор-тюрколог М.Бакировның әлеге монографиясе хәзерге ориенталистика фәненә үзенә бер аерым әһәмиятле, мөһим вакыйга булып тора, чөнки борынгы төркиләрнең этногенезы, этнокультурасы һәм этнолингвистикасы буенча булган аз санлы фәнни хезмәтләргә беренче тапкыр шундый яңа, уникаль һәм саллы хезмәт килеп өстәлде. Бу китапта моңа кадәр булмаган глобаль характердагы, яңа һәм оригиналь концепциянең барлыкка килүе бәян ителә; ул концепция шуннан гыйбарәт: иң борынгы чорда төрки телләр бердәмлеге Якын һәм Алгы Азиядәге бердәм ареаль союз составындагы тугандаш (агглютинатив) һәм тугандаш булмаган (флектив) телләр лексикалары һәм тарихи грамматика үзенчәлекләренең үзара аралашуы, кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән».

2022 елда М.Бакиров җәмәгатьчелекне тагын бер яңа хезмәте – «Тайны происхождения наших предков» исемле монографиясе белән сөендерде. Бу хезмәттә дә галим үзенең тикшеренүләрен масштаблы итеп, күптөрле фәннәр казанышларын актив файдаланып алып бара.

Монография ике бүлектән тора. Беренчесе «Болгар һәм татарларның аз билгеле булган этник тамырлары» дип атала. Анда галим мондый мәсьәләләргә тукталa: болгарлар – җирле һәм күчеп килгән кабиләләрнең үзара кушылуыннан барлыкка килгән; хазарлар һәм барсиллар этник тарихларының болгарлар белән кушылып үрелүе; савир/суварлар – болгарларның этник берлеге кабиләдәшләре; болгар, татар һәм кыпчакларның бердәм этнос булып берләшүе. Шушында ук ул Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының язылу урыны нәкъ менә Болгар дәүләтендә булуын күп дәлилләр китереп исбатлый; шул ук чорда иҗат ителгән, моңа кадәр фәндә билгеле булмаган «Ана вә угыл» исемле 246 юллык поэма текстын фәнни кулланылышка кертә.

М.Бакировның прото- һәм пратөрки теленең иң борынгы һәм иң архаик сүзлек составын чагылдыра торган, борынгы чордагы Алгы Азия һәм Төньяк Африка территорияләрендәге ареаль телләр союзында гамәлдә булган лексик-семантик сүзлекне барлыкка китерүе үзе үк галимнең зур уңышы булып саналырга хаклы (бу сүзлек Алгы Азия һәм Төньяк Африка территорияләрендәге ареаль телләр союзында гамәлдә булган 752 лексик праформаны үз эченә ала). Бу сүзлек шушы өлкәдә эшләгән галимнәр өчен киләчәктә кыйммәтле чыганак булып хезмәт итәчәк.

Әлеге монографиядә тикшерелгән мәсьәләләрнең тагын берсе – чуаш милләтенең формалашу тарихын аңлату. Элек галимнәр арасында чуашларны төрки халыклар ареалына кертеп караучылар да булды. М.Бакиров моңа кискен каршы чыга: күптөрле лексик мисаллар китерә һәм чуашларның чыгышлары белән үк фин-угор телле халык икәнлеген дәлилли.

М.Бакиров үз монографиясендә безнең бабаларыбыз – борынгы төркиләрнең иң борынгы ватаны Якын Көнчыгышта булганлыгын фәндә беренче булып һәм кире кага алмаслык дәлилләр белән исбатлый. Бу исә тюркология һәм Көнчыгышны өйрәнү фәне өлкәсендә зур ачыш булып тора. Шундый киң масштаблы, өр-яңа фикерләр белән тулы фәнни хезмәтләрне язып, Марсель Бакиров татар филология фәнен халыкара дөньяга чыгара.

М.Бакиров бүгенге көндә дә яңа үрләр яулап алу өлкәсендәге эшләрен дәвам итә. Быел ул «Мең дә бер фикер» дигән яңа китабын бастырды.

Әнвәр ШӘРИПОВ,
филология фәннәре докторы.

Халкыбыз һәм авылыбыз горурлыгы

Күптән түгел татар дөньясы РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт абый Әсәдуллинның 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Альберт Әсәдуллин 1948 елның 1 сентябрендә Казан шәһәренең Суконка бистәсендә туа. Казан шәһәренең 43нче мәктәбендә укый, шул ук вакытта рәсем сәнгате мәктәбенә йөри. 1966 елда Казан сынлы-сәнгать училищесын тәмамлый һәм ул вакытта Ленинградтагы И.Е.Репин исемендәге рәсем, скульптура һәм сәнгать институтының архитектура бүлегенә укырга керә. Монда укыган чорда кечкенә балачактан ачылган рәсем сәнгатенә булган сәләте белән янәшә әти-әнисеннән бирелгән җыр-музыкага булган таланты ачыла – Альберт абый ул чорларда үтә дә модада булган рок-группада җырлый башлый һәм бик тиз дан ала.

Ул «Призраки», «Фламинго» группаларында җырлый. 1968 елда комсомолның Ленинград өлкә комитеты оештырган «Питер» рок-фестивалендә катнаша һәм яхшы вокалист булып таныла.

Укуын дәвам итү белән бергә, җитмешенче елларда «Невские волны» группасында җырлый. 1974 елда институтны тәмамлый. Шушы чорда А.Васильев белән А.Журбин аны «Орфей һәм Эвридика» исемле беренче совет рок-операсына Орфей партиясен җырларга чакыралар. Шушы партия белән А.Әсәдуллин бөтен илгә, дөньяга таныла, күп чит илләрдә чыгыш ясый. Аның исеме Бөтендөнья джаз, поп һәм рок музыкасы энциклопедиясенә кертелгән, ул – Халыкара фестивальләр лауреаты.

1989 елда Идел Болгарстанының ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуга багышланган тантаналарда «Мәһди» исемле Коръән сюжеты буенча эшләнгән фолк-рок сюитасында төп партияне башкару аның милли сәнгатькә тирән мәхәббәтен күрсәтте. Ул үзенең дөнья һәм Россия сәхнәләрендәге концертларында татар халык җырларын зур осталык белән башкара, милли сәнгатебезне пропагандалый.

А.Әсәдуллинга 1998 елда Татастанның халык артисты исеме бирелде. Ул Бөтендөнья татар конгрессының II корылтай делегаты булды.

Альберт абый үзенең туган җире дип Татарстанның Балтач районын атый. Чыннан да, аның әнисе Нәгыймә апай – шушы районның Ор, әтисе Нурулла абый – Чапшар авылыннан. Нурулла абый авылның оста гармунчысы булган, Бөек Ватан сугышында катнашкан, хәрби хезмәтендә полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Чапшарда Нурулла абыйның абыйсы, шулай ук Бөек Ватан сугышы ветераны, авылның элеккеге имамы Хәлил абыйның балалары, оныклары бик матур итеп яшәп ята, бу көчле һәм затлы нәсел. Хәлил абыйның улы Мулланур абый – укытучы, күп төрле һөнәрләр иясе, Чапшар авылының имамы, җәмәгать эшлеклесе. Альберт абый Әсәдуллин да җәй көннәрендә генә Чапшардагы Мулланур абыйларга кунакка кайтып, бер-ике кич кунып, этисенең туган авылына баш иеп, мәчеттә намазлар, догалар укып китте. Мулланур һәм Альберт абыйлар Әсәдуллиннар Балтачка, Ор, Субаш һәм Адҗим авылларындагы туганнары янына да барып кайттылар. Альберт абый элек тә Балтачка кайткалый иде. Әлбәттә, ул газиз туган ягын якын һәм үз итә, аның үзен дә Чапшарда, Орда, Балтачта көтеп алалар, аның белән горурланалар.

...Бер җәй чыккач, өстәп куймыйча да булмый. Әсәдулла бабайлар нәселен безнең якта бик хөрмәт итәләр иде. Әсәдулла этисенең Ярулла атын йөртүен беләм. Ул буын кешеләренә бик еш кына «Пугачлар» дигән сәер кушамат та тагылып йөри иде. Сәбәбе дә бик нигезле булган. 1740 елларда, ул замандагы патшабикә Елизавета Петровна фәрманы буенча, Казан өязендә төзеп куелган 536 мәчетнең 418 ен җимереп һәм яндырып юкка чыгарганнар бит. Ә чирек гасыр узуга Казан өязе җиренә Җаек илә Оренбург ягыннан «Петр Федорович галиҗәнапләре» – Емельян Пугачев гаскәре бәреп кергәч, безнең Чапшар авылыннан да дистәләгән ирләр аның «казаклары» сафына барып баскан. Мөгаен, аларның күбесен патша карательләре кырып бетергән яисә усал җәзага тарткандыр. Мәгәр исән калганнары да аз булмаган. Ярулла-Әсәдуллалар нәселе дә батыр рухлы, көчле һәм кыю булып дәвам иткән, әнә.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.

Үгет-нәсыйхәт остасы

Чапшар сигезьеллык мәктәбендә укыган 1970-1972 еллар иде микән, мәктәптә шундый сүзләр таралды, имеш, безнең мәктәпкә Илдус исемле бик атаклы лектор-международник килә икән. Ул шундый яхшы иттереп сөйли ди, белмәгән әйберсе юк, бик белемле кеше, җитмәсә, безнең авылның Гөлбәгъдә апаның улы да, ди. Без аптырап калдык.

Болай зурлап, Чапшар мәктәбендә укыганда ике генә кешене сөйләгәннәр иде. Аның икенчесе Пүскән авылында туган, хәзерге вакытта Чапшарда яшәүче кадерле укытучыбыз Тәгъзимә апайның абыйсы Борһанов Сәлим абый иде. Аны да бик белемле, урыс телен су шикелле эчә, дип, сөйләгәннәр иде.

Илдус абый чыннан да бик кызыклы лекция сөйләде. Без аптырап, кино артистларын караган күк сокланып, аның һәрбер хәрәкәтен күзәттек.

Юнысов Илдус Зөбәер улы 1939 елның 15 февралендә Чапшар авылында туган. 1957 елда Чепья урта мәктәбен тәмамлый һәм колхозда эшли башлый. 1961 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Тиздән матди кыенлыклар аркасында читтән торып укуга күчә һәм укытучы булып эшли башлый. Аңа Чутай, Сәрдек һәм районыбызның башка мәктәпләрендә эшләргә туры килә. Шушы елларда ул үзен халык арасында агитация-пропаганда эше остасы итеп таныта – аның лекцияләрен авылларда көтеп алалар, пропагандист булачак аның дәресләре башкалар өчен үрнәк була. Тырышлыгын күреп, 1968 елда аны КПССның район комитеты аппаратына алалар. Ул агитация-пропаганда бүлеге инструкторы, шушы бүлекнең мөдире була. 1968 елда университетны тәмамлап, диплом ала, әмма үзенең белемен күтәрүне дәвам итә – 1982 елда КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы марксизм-ленинизм университетын, 1987 елда республика лекторлык осталыгы университетын тәмамлый. Район лекторларының һәм пропагандистларының остазына әверелә.

Шушы елларда И.Юнысов район һәм республика матбугатында тормышыбызның актуаль проблемалары турында мәкаләләр, районыбыз тормышы, аның кешеләре турында матур язмалар белән катнаша башлый. Ул районыбыз тарихын барлау, туплау һәм халыкка ирештерү буенча гаять зур хезмәт башкарды. Бу хезмәте аңа районыбыз халкының тирән хөрмәтен китерде. 1990 елда И.З.Юнысовка Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән абруйлы исем бирелде.

Илдус абый 1995 елның 1 маенда йөрәк өянәгеннән кинәт вафат булды.

Илдус абыйның әнисе Гөлбәгъдә апай да Чапшарыбызда 1989-2008 елларда абыстай булып торды. Без зиратка барып әти-әни, туганнарның, авылдашларларның каберләрен караганнан соң, махсус Гөлбәгъдә апай янына барып сәдакә бирեп, догалар укыта идек. Ул бер кечкенә генә өйдә торды, авылыбызга, кешеләргә күп яхшылыклар эшләде, гомерен ислам динен күтәрүгә, үстерүгә багышлады. Илдус абыйның да, әнисе Гөлбәгъдә апайның ла исемнәре авылыбыз Чапшар, районыбыз Балтач тарихына алтын хәрефләр белән язылган.

З.ХӘЙРУЛЛИН.

Мөхәммәт МИРЗА

Багышлаулар

ХАЛЫК ӘЙТСӘ...

(Нәкый ага Исәнбәткә)

Табып тарих төпкеленнән
Чыгарды җәүһәрләрен...
Туган халкының хак сүзен –
Мәкале-мәрҗәннәрен.

Дастаннарын җәеп салды:
Гыйбрәтләр алыр өчен.
Җаһилләрнең хөкеменнән
Шәт йолып калыр өчен.

Исәнбәтләр исән чакта
Җилгәрде гыйлем чүбен.
Искедән ис чыгармакчы
Ниндидер кара чебен?

Алтын тәңкә аунап ятмый,
Ягылмый нәҗес-кара.
Халык әйтсә – туры әйтә:
Эт өрә – кәрван бара.

Хакыйкатьне бар Хак белә –
Имансыз залим түгел.
Вакыт сынавын үтмәгән
Көнлекче галим түгел.

Көнлекчедә – бәндәчелек,
Ихтыярый мескенлек...
Милләтнең хак хезмәтчесе –
Исәнбәттә өстенлек!
Сентябрь,2023

* * *

Халкыбыз каһарманы Сөембикә Ханбикәнең тууына 500 ел тулу да битараф тынлыкта узып китте.

И ханбикә, исемеңне тапладылар,
Синнән яман гаепләне тапмадылар...
Хакыйкатьтә: күрәләтә яла ягып,
Үзләренең хыянәтен акладылар...
...Тарихында шөһрәт тоткан шул халыкны
Тары ярмасыдай төеп вакладылар...

* * *

Милли театрыбызның мәшһүр трагигы Мохтар Мутинның тууына 135 ел тулу да, гадәттәгечә, билгеләп үтелмәде...

Синнән элдә шикләнәләр икән,
Шүрлиләр икән ич, и Мохтар...
Шәһитләр дә шаһит була ала:
Исхакый кисәткән афәт килде:
Милләтеңне кайтып син коткар.
Сентябрь, 2021

СУБАЕН ТЕРӘП ТОРСАК ТА

(Әмирҗан ага Моталлаповка)

Сорауны дөрес куясың:
Кыланмый кырыс куясың
Җавапларым шәт булса да,
Әрнү-сагышка тулса да,
Юатып ни әйталам соң,
Дәшми басып торамын...

Түреңә үк үтәр идем,
Беләм, урын табарсың...
Сызлавыңа сары маем
Килә бик тә ябасым...
Туксаныңда да сафтан-саф
И, нарасый бала Син...

Без күргәнне кемнәр күргән:
Сугылып та сөрелеп
Шахталарга төшеп чаптык
Себер, котып күмерен –
Кырып бетерерлек түгел
Җанга сеңгән сөремен...

Сорауны дөрес куясың,
Җавабы кыска, кырыс:
Субаен терәп торсак та,
Ил түре безгә – бусага?..
Сорыйм: – Туксаның тулса да,
Нык тор, сынмаска тырыш!
Июнь, 2023

* * *

(Мөдәрис энемә)

Мәгыйшәтле нәсел-ыруының
Өметләр баглаган төпчеге
Дәверләргә бәйләп, алга әйдәп
Әләндерә гомре көпчәген.
Риясызга мең рәхимле Бер Хак
Исәп-хисап көн килачәген
Син белеп тор, энем, онытма
Саваплар кыл – өстәләчәген.

ЕЛЪЯЗМАЧЫ

(Илшат Халиуллинга)

Яланаяклы балачак иленнән
Үр, үткелләр имин үтеп киленгән.
Мосафир чакрымнарын кем санасын? –
Иманыннан чигенмәсен иң элгәр.

Бистәләрдән дистәләгән ырулар
Кубарылып кыйтгаларга сибелгән.
Ятка яраклаша Адәм баласы –
Бәндәчелек бөгелдертә биленнән.

Юлъязмачы, елъязмачы нияте: –
Йолу хакны нахак җаһил җиленнән.
Иманына бәрабәр фидаилык
Галимнәргә, шагыйрьләргә бирелгән.

Шөкер, җәүһәрләргә тиң дастаннар
Елъязмачы биштәрендә, иңендә...
Май, 2023

ЯШЬНӘП ЯШӘЛГӘН ГОМЕР

(Дамир Җәлиловка)

1

Чор, дәверләр алышына,
Ел фасыллары кебек.
Үзгәреп тора төсләре,
Хәтта өлгереми каласың
Асылына төшенеп.

Чор, дәверләр алышына,
Соралмый сәбәпләре.
Гомерләрнең агышына
Сынауларын тезеп куя –
Соңартмый сәгатьләрен.

Һәр инсан үз дәверенең,
Үз чорының баласы...
Гомер иткән һәр көнендә
Дөньялыкның сиратыннан
Кемнәре чыгала соң?

Сынау арты сынау тоткан
Чорларда гомер иттек,
Үткәннәрдә үкенү юк:
Җидесеннән җитмешенең
Үренә менеп җиттек!

2

Гомерләрнең агышында
Һәр фасылның үз төсе,
Һәркайсы чиксез мөкатдәс:
Туган оям, Гаиләм, Илем –
Бар кыйммәтләрдән өстен!

Тамырыма сутын салган
Бабамның дәвамы мин,
Әбкәм, Әнкәм сөте сеңгән
Хилафсыз иманлы җаным –
Догалы, дәвалы мин!

Яратылышыннан алып,
Тамырларыбыз җирдә:
Кишәрлеккә бүленеп тә,
Кумәк көннәр күрелеп тә
Иҗтиһат иттек Илдә.

Солдат булдык Ил сагында
Себер салкыннарында.
Сынмадык һич сынатмадык
Туган җирдә сагнып көткән
Тугры ярлар барында...

...Ярты гасыр туган җирнең
Олтаны булдык – шөкер,
Сакладык – сатмадык аны:
Гаделлек һәм тугрылыкның
Солтаны булдык – шөкер!!

3

Түренә менеп җитсәк тә
Калмабыз һич тукталып:
Офыкта менәсе мең үр –
Иңнәрдә әлдә Ил йөге,
Сикәлтәле сукмагы.

Үр менүләр – урау-урау
Түбәнгә төшү ансат...
Мең үр артында – мәңгелек:
Барып җитәрме оныклар,
Әгәр без туктап калсак?!

Чор, дәверләр алышына,
Куласасы әйләнеп
Бер басар да таныр дөнья
Яшьнәп яшәлгән гомернең
Төсмерләрен – шәйләнеп!!!
1 октябрь, 2023
Актаныш.

МИН СИНЕ ЧАКЫРАМ БИЕРГӘ

(...үзебезгә)

Мин сине чакырам биергә,
Гомеремнең көзге вальсына:
Үткәннәрне тезеп хәтердә
Әйләник тын гына, бер тында,
Ярсыма, йөрәгем, ярсыма!

Мин сине чакырам биергә,
Хәтердә чаптардай чакларым:
Ярсудан тилереп чапканым.
Әйләник тын гына, бер тында
Сүндерми күңел учакларын!

Хәтердә бүгендәй барсы да:
Чаптарларны узып чапканым,
Югалтып янәдән тапканым...
Ярсыма, йөрәгем, ярсыма
Гомремнең иң соңгы вальсы ла?!

Адәм баласы

(Бишьюллыклар)

* * *
Асылташ, мәрҗәннәр
Тирәндә ятадыр...
Адәм баласының
Шунар табынуы –
Кыйммәтле хатадыр.

* * *
Күзенә чалыныр –
Кулы көрәп алыр;
Адәм баласының
Бар ниятен чынга
Нәфесе ашырыр.

* * *
Мөнәсәбәтләрдә
Холкы – биек киртә...
Адәм баласының
Киеренкелеккә
Кирелеге илтә.

* * *
Күмәк йортта низаг:
Өстә дә, аста да.
Адәм баласының
Күршеләре нирад –
Катырак басса да.

* * *
Ярлылык өстенлек
Булудан туктауга
Адәм баласының
Өянәге купты
Мал-мөлкәт туплауга.

* * *
Бикле ишекләре –
Ишәя шикләре:
Адәм баласының
Кем килеп, ник япкан
Тошык-тишекләрен?..

* * *
Кар астыннан чыккан
Кәлҗәмә-бәрәңге: –
Адәм баласының
Үлемнән коткарган
Тәгаме – хәләлме?

* * *
Камалып яуланган
Ауган бу калалар...
Адәм баласының
Биш гасыр йөрәген
Әрнетә яралар.

* * *
Ай да күралмый ди
Җирнең аргы ягын...
Адәм баласының
Күрәлмәгән төсле
Үзенең колагын...

* * *
Күз – күңел көзгесе,
Сүз – акыл сөреше.
Адәм баласының
Күреп әйткәненең
Саллы фикри төше...

* * *
Көн туса бер сорау:
Кая чаба вакыт,
Адәм баласының
Бер саплам гомренең
Бәрәкәтен ватып?..

* * *
Имана, кишәрлек –
Мөлкәте саналган...
Адәм баласын кем
Хәләл өлешеннән
Биздергән, талаган?

* * *
Тыйганнан тыйдырган
Йола, әдәпләре: –
Адәм баласының
Баләдән – башаяк
Иткән таләпләре.

* * *
Тураеп басарга
Тотыныр җае юк...
Адәм баласының
Колбиләүчесеннән
Котылыр шәе юк.

* * *
Ерак үткәннәрнең
Ачыла серләре –
Адәм баласының
Туар көннәренең
Чуар төсмерләре.

* * *
Күзгә карап чаба –
Балтасы кулында.
Адәм баласының
Сөяк-сынаклары
Уңында, сулында.

* * *
Тарихта баскынчы:
Килгән, күргән, алган.
Адәм баласының
Ирекле укмашы –
Күрәләтә ялган...

* * *
Әбиләр чуагы
Уятып иртәдә
Адәм баласының
Күңлен моңга төрә
Кылына чиртә дә.

Михаил Худяков

(Дәвамы. Башы 45, 46 нчы саннарда).

1552 ел явында катнашучы кенәз Курбский төньяктан торып Казанны болай тасвирлый: «Казан елгасына каршы тау шулкадәр биек ки, аны күз карашы белән иңләү кыен; аның өстенә кала урнашкан һәм патша пулатлары һәм бик биек таш мәчетләр, анда аларның үлгән патшалары җирләнгән; хәтерләвемчә, алар бишәү». (Курбский, с.17). Шул рәвешле, калада ерактан үз биеклекләре белән аерылып манаралы 5 таш мәчет күренеп торган. Аларның барысы да Кремль калкулыгында булганмы – мәгълүм түгел. Шунда булулары да бик мөмкин. Берничә мәчетнең торуы шөбһәсез. Курбский язуынча, хан сарае «пулатлар һәм таш мәчетләр арасында» урнашкан була (Курбский, с.27). Без инде ике мәчет хакында яздык – берсе хан сарае янында, икенчесе Нургали мәчете. «Царственная Книга»да Кол Шәриф мәчете дип аталган Җәмигъ мәчете исә Кремль калкулыгының көньягында, Таҗик ермагы янында – урыслар Спас монастыре салган урында була. Мәрҗани әлеге мәчет хакында Казан татарлары арасында сакланган риваятьне хәбәр итә: аның сигез биек манарасы булган икән («Мостафад әл-әхбар»). Аның янында Галия мәдрәсә эшләгән, биредә мөселманнар югары дини белем алган. Урыслар Казанны басканда «Христианнар мәчеткә, Таҗик ермагы янындагы Кол Шәриф мәчетенә якынлашты, һәм монда Кол Шәриф мулла янына күп динсезләр җыелып аяусыз сугыштылар» (Царств. Книга, с.306). Кенәз Курбскийның тулырак хәбәре урысларга иң соңгы дәһшәтле каршылыкны Кол Шәриф җитәкчелегендә мәдрәсә шәкертләре һәм мөселман муллалары күрсәтүен раслый: «Кол Шәриф мулла исемендәге бөек бискуплары, үзләренчә әйткәндә, бөек әмирләре алда булып, аның белән хафизлары, сәидләре, муллалары безгә каршы чыкты, безнең белән шулкадәр каты сугыштылар ки, барысын да кырып бетердек» (Курбский, с.29).

Шулай итеп, Кремль калкулыгында шәһәрнең төп өлеше урнашкан була. Биредә дөньяви һәм рухани идарә туплана (хан сарае һәм Кол Шәриф мәчете), затлы нәсел вәкилләренең торак биналары (Ширин бәкләрнең сарае) югары уку йорты һ.б. Кремль калкулыгыннан берничә урам һәм тыкрык сузылган; 1566 елда биредә буйга 2 урам һәм берничә тыкрык була – Түбән капкасына таба (хәзерге Килриан һәм Юстина чиркәве белән Спас монастыреның иске коймасы арасында), Сбойлы капкага таба (хәзерге Консистор тыкрыгы) һ.б. Кремль калкулыгының Воскресенски урамына караган итәге хәзер тигезләнгән, ләкин таш арасыннан баш төрткән үләннәргә карап, бу төшнең узган гасырларда нинди булуын күзалларга мөмкин.

Воскресенски калкулыгы

Кремль калкулыгын Воскресенскиныкы белән тоташтырып, Таҗик ермагы аша күпер салынган. Ермакның төньяк яры текәрәк, көньяк яры сөзәгрәк булган. «Таҗик» сүзе ул заманнарда сәүдәгәр мәгънәсендә йөргән. Ермакның шулай аталуы янәшәдә сәүдә үзәге – базар булуына ишарәли. Чыннан да, Битекче кенәгәсе Таҗик ермагы янында, хәзерге Гостиный двор урынында «торг» булуын хәбәр итә. Күрәсең, Казан ханлыгы тар-мар ителгәч тә, базар үз урынында калган, урыслар аны шәһәрнең бүтән почмагына күчерү белән мәшәкатьләнмәгән. Базар – һәрбер шәрекъ шәһәренең үзәге. Татар базарының урыс рыногы белән чагыштырганда үзенчәлеге шунда – базар урамының ике ягыннан, кибетләр янәшәсендә, түбәле озын һәм тәбәнәк галереялар сузыла. Җәй көне салкынча, кышын һәм көзен коры булган әлеге тәбәнәк галереяларда һәрвакыт халык кайнашкан, кечкенә һәм тәрәзәсез ярым караңгы кибетләрдән кеше күзенә чыгарылган тауарлар тау-тау өелгән. Казанның татарлар тоткан Печән базары әле дә нәкъ шул рәвештә. Базардан ерак түгел генә төп сәүдә һәм финанс оешмалары урнашкан, һәм Битекче кенәгәсе урыс Казаны чорында монда таможня ызбасы һәм важня – бизмәннәр өчен махсус йорт булуын хәбәр итә (Писц. книга, с.57). Татар дәверендә дә әлеге оешмаларның базардан ерак тормавына шикләнмәскә мөмкин.

Сәүдәгә мәхәббәтне, сату-алу өлкәсендә булдыклылыкны татарлар болгарлардан мирас итеп алган. Казандагы базар әле дә шаулап тора, һәм ул, шөбһәсез, Казан ханлыгы вакытында да шундый булгандыр. XIX гасыр ахырында Н.П.Загоскин Казандагы татар базарын болай тасвирлый: «Печән мәйданы янындагы татар базарында сез һәрвакыт төркем-төркем татарларны очратасыз, аларның кайсысы сәүдә эше белән мәшгуль, кайсылары үзара әңгәмә куерта, бер-берсенә яңалыклар һәм хәбәрләр җиткереп тәккә йөрүчеләр дә җитәрлек. Базарга яки ярминкәгә килгән һәр татарның йөрәге җилкенә, чөнки сәүдә – аларның җаннарына якын һөнәр. Сәүдә белән татарлар базарда гына шөгыльләнми, аларны шәһәрнең һәр төшендә очратырга мөмкин: әле бер урында лимон, алма һ.б. саталар, әле икенче урында иске-москы җыялар... Бер карыйсың – алар аукционга, әҗәт бирү кассасына, кемнеңдер мөлкәтен сатуга куйган төшкә ашыга. Гомумән, ваклап сату сәүдәсе күбесенчә татарлар кулында. Вак сәүдәгәрләрдән кала татар базарында һәм бүтән сәүдә үзәкләрендә капиталист татарларны да, заводчикларны, коммерсантларны, эре торгашларны очратырга була. Аларны тануы җиңел – болар токымлы, симез айгырлар җигеп йөрергә ярата, башларында алтын белән чигелгән түбәтәйләрен каплап, кыйммәтле бүрек кукраеп утыра. Бай татарларның мәнфәгате сәүдә белән генә чикләнми, алар үзара шәһәргә кагылышлы эшләр турында сөйләшә, бүтән мөһим мәсьәләләрне хәл итә». Биредә автор сәяси һәм иҗтимагый тормышны күздә тота (Н.П.Загоскин. «Спутник по Казани», с.513-514).



Казан кирмәне, XV гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

Шәһәрдә мәчетләр күп, татарлар динилек белән аерылып тора. Аларның һәр авылында мәчет бар, зурракларында мәктәпләр икәү һәм күбрәк тә. Хәзерге вакытта Казанда 30 мең кешегә 15 мәчет бар: 9 – Иске Татар бистәсендә, 4 – Яңа Татар бистәсендә, 2 – Адмиралтейскида. Кенәз Курбский Казанда «бик биек» 5 таш мәчет торуын язган, агач мәчетләр, һичшиксез, бик күп булгандыр.

1793 елда Гостиный дворның Кара күлгә караган көньяк-көнчыгыш өлешендә, нигез казыганда зират калдыгы табыла. Аннан чыккан кабер ташы хәзер Мәрҗани мәчетендә саклана. Анда болай язылган (хәзерге телгә тәрҗемә): «Алла Тәгалә әйтте: дөньядагы бөтен нәрсәләр бетәчәк, бары олылыкка һәм хөрмәткә лаек Аллаһ үзе генә мәңгелек. Тугыз йөз утыз алтыда Шаһмөхәммәд бәк углы Мөхәммәдгали бәк зөлкагдә аенда (ай хисабынча 11 нче ай) кяфер кулыннан шәһид (китте)».

Уң ягында мондый язу: «Каләән-нәбие галайһиссәлам: әд-дөнья сәгатән фә-әҗгаләһә тәгатән» (Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйтте: дөнья – бер сәгатьлек, сез аны гыйбадәт белән үткәрегез). Ташның аркасына: «Бу ләүхәне углы Тәңре Колый бәк бина кылды» (Бу ташны мәрхүмнең углы Тәңре Колый бәк ясатты), дип язылган. Һиҗри 936 елның зөлкагдә ае милади 1530 елның июленә туры килә. Бу вакытта урыслар белән казаннар арасында сугыш булуы тарихтан билгеле, һәм Мөхәммәдгали бәкнең нәкъ шушы яуда баш салуына шикләнмәскә мөмкин.

Казанның җир асты юлларын тикшерүче проф. М.М. Хомяков, Казан урамындагы башта А.А.Кремлевның, аннары А.Н.Харитоновның милке булган, хәзер «Шәрекъ» (элекке «Өмет») басмаханәсе урнашкан бинаның Казан ханлыгы дәверендә Сөембикә йорты булуы хакындагы риваятьне язып калдырган: «Казан урамындагы Харитонов йорты турында төрле риваятьләр йөри. Миңа бу йорт турында болай сөйләделәр: 30-35 еллар элек хәзер Харитонов типографиясе (борын заманда Сөембикә йорты дип аталган) торган төштә урам уртасыннан ирләрнең рухани училищесына таба канау казыганнар. Канау төбендә эшчеләр бихисап баш сөякләре, скелетлар, татар заманыннан калган көмеш тәңкәләр тапкан. Шул ук вакытта элекке Сөембикә йорты астында яшерен юл булуы ачыкланган... Телдән-телгә күчкән бу сүзләргә таянмыйча, бу хәбәрнең чынлыгын шәхсән үзем тикшерергә булдым... Харитонов йортны Кремлевтан сатып алган. Мин аңардан бу хакта белгәннәрен сөйләүне үтендем. А.А.Кремлев йорт астында яшерен юллар юклыгын, бары тик тирән подваллар булуын әйтте. Подвал стеналарын хасил иткән ташлар Кафедраль соборның нигезенә куелган ташларга охшаган икән. Чиркәү йортын салыр өчен нигез казыганда, аның йорты каршында, чыннан да, җир астында татар кулъязмалары белән тулы бинага юлыкканнар. Элекке Кремлев йортын төзекләндергәндә күзәтеп торган И.И.Аристов җир асты юлларының табылмавы турында хәбәр итте. Купенников йортына (соңрак Чернояров йорты) терәлеп торган стенада томаланган элекке тәрәз эзләре табылган. Харитоновның ризалыгын алып, И.И.Аристов белән бергә без әлеге йортның идән астын янә тикшереп чыктык. Мине диварларның калынлыгы шаккатырды. Мәсәлән, литография бүлмәсендә ул 36 карыш иде (1 метр 60 см тирәсе – тәрҗ.). Идән асты бүлмәләренең берсендә без чыннан да 21 карыш киңлегендәге уем таптык – бу җир асты юлының томаланган авызы иде. 3 нче катта, җиз кою бүлегендә, 1 аршын киңлектә, 3 аршын биеклектә шундый ук уем бар иде». (М.М.Хомяков «К вопросу о подземных ходах г.Казани». Отд. оттиск из XXVl т. «Известий Общества Археологии, Истории и Этнографии» за 1910 г. С.2-3).

Проф. Н.П.Загоскин Воскресенски һәм Гостинодвор урамы чатында торган, әүвәл Месетников, аннары Чарушин милке булган йорт хакында да шуңа охшаш мәгълүматны хәбәр итә. «Спутник по Казани» хезмәтендә «Казанның җир асты юллары» дигән аерым бүлек бар: «Кремль урнашкан тау һәм шәһәрнең аңа терәлеп торган өлешләре җир асты юллары белән челтәрләнеп беткән, дигән риваять җирле халык арасында киң таралган. Гостиный двор чиркәвен реставрацияләгәндә дә җир асты юлына тап булганнар, дип сөйлиләр.

китабыннан өзекләр

Воскресенски урамында һәм Кремльгә якын тыкрыклардагы йортлар (Месетников, Кремлев, Боратынский йортлары) астыннан, ә аларның подваллары йортларга караганда күпкә борынгырак, Кремльгә таба җир асты галереялары үтә дип ышандыралар. 1894 елда Археология, Тарих һәм Этнография җәмгыяте, халык арасында йөргән шул сүзләр нәтиҗәсендә, Месетников йортының идән асты корылмаларын тикшерде. Җир асты юллары табылмаса да, әлеге тикшеренү бик нәтиҗәле булды. Борынгы нигезгә салынган бу йортның идән асты корылмасы өч катлы, бик күп бүлмәле, күп санлы менү-төшү юллары булган гөмбәзле бина икән. Әлеге бинаның 5-6 сажин тирәнлектәге аскы каты, табигый ки, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы иде; кирпечләрнең зурлыгыннан аларны кую рәвешеннән диварларның бик борынгы, татар Казаны дәвереннән үк калганлыгын фараз итеп була. Аскы катның кырый диварларында томаланган уемнарның эзе күзгә ташлана. Кызганычка күрә, бу ярусның бүлмәләре яртылаш вак таш, туфрак белән тулы, шуңа күрә бу үзенчәлекле катакомбаларны җентекләп тикшерүе кыен. Месетников йортының өстән-өстән генә тикшерелүенә (җир асты корылмаларының планы да төшерелмәде) үкенергә генә кала. Һәм шушы тикшерү белән Казан җир асты юлларын өйрәнү тәгәлләнде дә» («Спутник по Казани», с.105-106). 1909 елда проф. М.М.Хомяков әлеге йортны яңадан карап чыга: «Ишегалдында башланган озын коридор йортны әйләнеп чыга, Воскресенски урамының тротуары астыннан үтә. Без шул коридордан яртылаш күмелгән тәрәз каршына килдек. Вак ташлар һәм чүп өстеннән шуып төшеп ниндидер подвалда аякка бастык. Электр фонареның яктысында бу залның буе 16 адым, киңлеге дә 16 адым булуын ачыкладык. Идәненә таш җәелгән, уртада бинаны тотып торучы таш багана, 1 сажин югарылыкта урамга караган тәрәз уемнары: аларның берсен Кара күлгә төшкән якта чамалап була әле, калганнары Воскресенски урамы кимәленнән 2 аршинга түбәндәрәк урнашкан. Почмакка агач баскыч терәлгән. Бер аркада яңа казылган өн бар иде. Йорт хуҗасы аны 1895 елдан соң казыган, диделәр» («К вопросу о подземных ходах г.Казани», с.3).

Әлеге мәгълүматларда һәм халык арасында йөргән риваятьләрдә сүз бер урын – Воскресенски калкулыгыннан Мунча һәм Кара күлләргә төшү юлында янәшә утырган Баратынский йорты, «Шәрекъ» басмаханәсе, Чернояров һәм Чарушин йортлары хакында бара. Шул ук төштә (Чернояров йортына каршы) Мөхәммәдгали бәкнең кабер ташы табылган. Кызганычка күрә, әлеге йортларның борынгы идән асты корылмалары моңача өйрәнелмәгән, археологик тикшеренүләр үткәрелмәгән. Югыйсә, җир астындагы диварларның салыну рәвешенә карап, аларның татар чорыныкымы, урысныкымы икәнлеген җиңел ачыклап булыр иде. Биредә татар дәвере биналарының җиргә иңгән калдыклары саклану мөмкинлеге зур. Чөнки Казанда әле XVIII гасырда гына салынган биналарның да (мәсәлән, Вознесение һәм Богоявление чиркәүләре) шактый өлеше җиргә иңүе безгә билгеле.

● Казан кирмәне, XIII гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

Бистәләр

Башкаланың чикләре Казан кирмәне белән генә төкәнми: кальга диварлары кырында бистәләр урнашкан була. Казан бистәләре чыганакларда күп тапкыр телгә алына (ПСРЛ VI, с.156; XIX с.254, 52; Царств. Книга, с.166, 194, 200, 201). 1469 елда бистәне яндырганда «күп бесермәннәр һәм татарлар христианнар кулына төшәргә теләмичә, үзләренең байлыкларын өстен күреп, мәчетләрендә, йортларында бикләнеп, үз мал-мөлкәтләре өстендә хатыннары, балалары һәм якыннары белән янып үлделәр». Проф. С.М.Шпилевский яза: «Елъязмадагы бу мәгълүматтан күренгәнчә, Казан бистәсендә яки бистәләрендә күп кеше яшәгән; биредә байларның йортлары урнашкан булган». (Шпилевский, с.440). Ул болай дип тә өсти: «1530 елга нисбәтле Казан бистәсе турындагы хәбәр анда бихисап кеше яшәвенә янә бер дәлил» (Шпилевский, с.441). Бистәләр коймалар («острог») белән урап алынган була. 1500 елда Урак бәкнең һөҗүме вакытында «Казан патшасы шәһәр кырында коймалар корырга боерды» (ПСРЛ VI, с.240) 1530 елда Казан хөкүмәте «якындагы күп чирмешләрне җыеп китерде һәм Болак янында, бистә тирәли коймалар корырга боерды, һәм Арча кыры буйлап, Болактан Казан елгасына кадәр койма тирәли урлар казытты, анда килгән кешеләр белән чирмешләр урнашты, шәһәргә дә ярдәм булыр, бистәне дә янгыннан саклар дип... Казан кирмәне үзенең артык зур булмавы аркасында барлык халыкны, килгән кешеләрне бигрәк тә, сыйдыра алмый, шуңа күрә патша әмере белән бистә коймасын таш һәм туфрак белән ныгыттылар, ул ике очы белән кирмәнгә килеп тоташты» (ПСРЛ, XIX, с.37).

Бер бистә шәһәрнең түбән очында, кирмән белән Болак арасында булса, икенчесе кирмәнгә Арча кыры ягыннан килеп терәлгән. Кала белән Кабан күле арасында буш җирләргә йортлар салынмаган була. Кенәз Курбский яза: «күлдән ул урынга (шәһәргә) ярты чакрым ара бар иде» (Курбский, с.16). 1552 елда Казанны камаганда «Шаһгали патшага һәм воеводаларга Кабан күле янындагы Болакның югары өлешеннән Арча кырына барырга» диелә (Царств. Книга, с.264); «Шаһгали патша һәм воеводалар Болактан менеп Арча кырына урнашты» (Царств. Книга, с.268); кенәз Курбский хәбәр итә: «Аларга нужаланып тауга – ул урын белән (шәһәр) – Кабан арасындагы Арча кырына барырга туры килде» (Курбский, с.17). Урыслар тарафыннан шәһәрнең Кабан күленә таба киңәйтелүе турында Битекче кенәгәсе хәбәр итә (Писц.книга, с.51).

Кирмән белән Болак арасындагы бистәдә чыганаклар ниндидер Таһир салдырган җәмәгать мунчасының таш бинасы турында хәбәр итә. «Царственная Книга»да әйтелә: «Болакның – теге (көнчыгыш) ягында... кирмән дивары астында Даирныкы дип аталган таш мунча» (Царств. Книга, с.269). 1552 елның 4 сентябрендә шартлатылган җир асты юлы «ул таш мунчага якын» була, һәм аңа таба казып керүне менә Таһир мунчасыннан башлыйлар (Царств. Книга, с.285). Шәһәр камалышта вакытта җәмәгать мунчасының таш бинасы Сакчы полкның фронт сызыгында була, ә ул «Болак тамагында» торган; җир асты юлының артык ерак булмавы да Таһир мунчасының хәзерге Тайницки капкадан ерак түгел Болак тамагына якын салынуын сөйли.

Арча кыры ягыннан кирмәнгә терәлеп торган бистәдә чыганаклар мөселман зираты булуын хәбәр итә. 1552 елда кенәз В.А.Старицкий чирүе «Хан капкасына каршы бистәдә зират янында» торган (Царств. Книга, с.298). Битекче кенәгәсе «Болакка таба ермакның ике ярында иске татар зираты» булуын искәртә (Писц. Книга, с.50). Шулай итеп, зиратның урыны Хан капкасы һәм Болакка таба сузылган ермак белән билгеләнә. Хан капкасы хәзерге Николай мәйданында торса, Болакка сузылучы ермакны Рыбноряд ерынтысы белән тәңгәлләштерә алабыз, нәтиҗәдә зиратның урынын Рыбноряд урамы башланган Нечаев калкулыгында дип билгели алабыз. Бу фаразга «Царственная Книга»дагы хәбәр дә каршы килми. Ул Шаһгалинең «Болак артында зират астында» урын биләргә әмер алуын җиткерә. Һәм, ди, «ул (Шаһгали) Болак аша чыгып, Арча кырына аяк басты» (Царств. Книга, с.263 и 268). Мөгаен, икенче зират Болак белән кирмән арасындагы бистәдә булгандыр: урыс чыганакларында бер урынны билгеләгәндә болай диелә: «Болакның югары өлешендә, Кораишка каршы, тау итәгендәге татар зираты астында»; урыслар бу урынны койма белән урап ала (Акты Исторические 1, N 162, с.299); әлеге мәгълүматлар бу урынның Университет тавында булуын күрсәтә.

Болак аша, әлбәттә, күперләр сугылган булган, ләкин чыганакларда без алар хакында хәбәр очратмыйбыз. Кенәз Курбский Болакны болай тасвирлый: «Болак үтеп булмаслык баткаклы елгачык, шәһәр астында ага һәм почмактагы маш янында Казан елгасына коя» (Курбский, с.16). «Казан елъязмачысы» яза: «Болак елгасы көчле янгырларда Казан елгасына агып чыга, бик болганчык, баткаклы, һәм бик тирән түгел» (ПСРЛ XIX, с.119).

П.Заринский хәбәр итә: «Татарларның Болак аша кичүне җайга салмаулары мөмкин түгел. Өлкән кешеләрнең сөйләвенчә, бу гасырның (XIX) башында, Болакны чистартканда, ләм астында калын имән такталардан тезелгән борынгы идәнгә юлыгалар» (Заринский, с.179). 1560 елларда Болакта – тамагында һәм бераз өстәрәк – 2 тегермән эшләп торган (Писц. Книга, с.47 и 48). Болак Казан елгасына икегә тармакланып койган, аларның берсе Черек Болак дип аталган.

Шәһәр яны

Бистәләрдән ерактарак шәһәр яны авыллары урнашкан. Безнең көннәргә аларның өчесе турында хәбәр килеп җиткән, болар – әрмән бистәсе, Кораиш һәм Бишбалта. Әрмән бистәсе Казанда кайчандыр Болгардагы колония рәвешендә урнаша. Болгарда «грек пулаты» («греческая палата») дип аталган чиркәү хәрабәләре янында әрмән зиратының эзләрен табарга мөмкин. Фарсы иле белән Кавказ арасындагы сәүдә бәйләнешләре әрмәннәр кулында булган. 1530 елда Казанда әрмән сәүдәгәрләренең яшәве «Казан елъязмачысы»ның авторы тарафыннан раслана (ПСРЛ XIX, с.130).

(Дәвамы киләсе санда).

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе

АЛИШ

Рафис КОРБАН

● **Абдулла Алиш үзенең гаиләсе белән. 1941 ел.**

(Дәвамы. Башы 46 нчы санда).

– Юк, сез йөрмисез, өйдә генә утырыгыз. Караңгы, кичке суык төшкән инде. Мин озак тормыйм, тиз әйләнермен. Сез әнә кыстыбый ашый торыгыз, – диде дә, Оркыя дәфтәрләрне түрдәге шкаф эченә куйды, аннары шәлен бөркәнеп, өйдән чыгып, тышкы ишекне биклә алды.

Малайлар кирогазда чәй кайнатып, әниләре табынга куеп калдырган кыстыбый белән сыйланды. Аннары Алмаз училищедан бирелгән өй эшләрен әзерләргә утырды. Ул ике ел инде Суворов исемендәге хәрби училищеда укып йөри. Елларда аларны өйгә кайтарып җибәрәләр. Шулай да өйгә эш бирергә онытмыйлар. Ә бу юлы яллары озын – аларны мартның соңгы көннәре булгач, язгы каникулга җибәрделәр.

Алмаз башта җиде яше тулгач Черек күл буендагы алтынчы мәктәпкә укырга кергән иде. Ул вакытта сугыш бара иде әле. 1943 нче ел. Беренче класстан соң, икенче елны укырга барыр алдыннан аларга урамда аның белән бер яшьләрдә генә булсалар да, чын солдат киемендәге ике малай очрады.

– Әни, карале, малайлар гына булсалар да, солдат гимнастёркасы кигәннәр, – дип аптырады Алмаз.

– Хәрби училищеда укыйдыр алар, – диде әнисе.

– Минем дә хәрби буласым килә! Училищеда укып, фронтка китеп, фашистларны дөмектерәсем килә. Ничә ел бара инде, һаман бетми шул сугыш!

– Бетәр, улым. Фашистларны үз өннәрендә кыйный башлады инде безнең солдатлар.

– Сугыш бетсә дә, илне дошманнардан сакларга кирәк булачак бит. Мин дә ил чигендә хезмәт итәргә телим.

Әнисенең бер дә укытасы килмәде Азмазны. Бигрәк тә дәү әнисе теләмәде. Училищега керү җиңел генә түгел икән. Малайларны бик җентекләп тикшерәләр. Мәктәптә алган белемен генә түгел, эти-әнисенең кем булуына да карыйлар. Җитмәсә, этисенең пленга төшүен дә искә алдылар, дип сөйләде әнисе.

Ләкин малай үз дигәнендә торды. Нәтиҗәдә икенче класска Суворов училищесына барды. Инде менә икенче уку елын бетереп килә. Тагын ике айдан өченче курс курсанты булачак.

Ада белән Алмаз бәләкәй чакларыннан ук дус булды. Мәктәпкә алар икесе бер класска барган иде. Училищега күчкәч кенә сирәк күрешә башладылар. Сугыш алдыннан аларның этиләре Фатих абыйны халык дошманы дип төрмәгә утыртканнар иде. Төрмәдән ул сугыш башланган елны, Яңа елны каршылаганда гына кайтты да, икенче көнне үк үз теләге белән сугышка китеп барды. Аларның әниләре – Кадрия апа белән Оркыя бик дуслар, гел очрашып торалар. Шуңа күрә дә этиләре турында яңалыкны иң беренче Кадрия апа белән уртаклашасы килде бугай аның.

Алмазга тыныч кына дәрес хәзерләп утырырга туры килмәде. Башта абыйсы китаплар алып үз эше белән утырганны күргән Айваз тынгылык бирмәде. Аңа этисенең «Ана әкиятләре» дигән китабын алып «Койрыклар» әкиятен укый гына башлаган иде, өч-дүрт хатын иярттеп, әниләре кайтып керде. Ул хатыннарның икесе – Мергасов йорты дип атала торган, алар белән берүк өйдә яшәүче Кави Нәҗми белән Ибраһим Гази исемле язучыларның хатыннары. Өченчесе – Аданың әнисе Кадрия апа. Ә дүртенчесен Алмаз танып белми. Ул да берәр язучы хатыныдыр инде.

– Менә, кызлар, нишләргә дә белмим – шатлык та, елата да, – дип, Оркыя шкафтан барып теге дәфтәрләрне алды да, берсенә дә бирергә теләмичә, күкрәгенә кысып тотты һәм, – Алишымның шигырьләре кайтты, – дип, елап җибәрде.

– Йә, балавыз сыкма әле! Кая, бир әле, күрсәт инде безгә дә, – дип, Сәрвәр аның кулыннан дәфтәрләрне алып, карый башлады. – Монысы Муса Җәлилнеке микәнни?

– Берсе Алишныкы, берсе – Җәлилнеке.

– Икесе бергә булганнар микәнни пленда? – дип сорады Кадрия.

– Бергә булганнар икән шул. Шигырьләрен дә бер кеше алып чыккан төрмәдән.

– Бу дәфтәрләрне алып килгән кешеме? Кем диден әле исемен?

– Ул түгел. Габбас Шәрипов исемле кеше, ди. Бу дәфтәрләрне китерүче – Нигъмәт Терегулов. Габбас Шәриповны, төрмәдән чыккач, Франциягә җибәргәннәр. Франциядә Алишның шигырьләрен берничә кеше үзенә күчереп алган, ди. Терегулов шуларның берсе икән.

– Мусаның дәфтәре калынрак.

– Алиш аз яза иде бит шигырьләрне. Күбрәк балаларга әкиятләр язды бит.

– Классик иде инде! Нимесләрнең бөек әкиятчеләре – бертуган Якуб белән Вильгельм Гриммнар кебек! Их, белделәр микән ул фашистлар нинди бөек әкиятче харап иткәннәрен?! – дип куйды Сәрвәр, Оркыяның сүзен куәтләп.

– Дания әкиятчесе Андерсен белән бер дәрәҗәдә иде Алиш! – диде Кадрия, аларга кушылып. Аннары ул Алишның дәфтәрен алды да, беренче битен ачып, шигырен укырга керешә:

Үзем турында җыр

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә,
Әйтер идем, кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.
Әйтсәләр дә, алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип,
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын, дип...

Кадрия бер-бер артлы берничә шигырен укыды Алишның. Аны тыңлап Оркыяның күзеннән тойлыксыз яшь акты да акты.

– Җитәр, Кадрия, укыма бүтән. Җәлил шигырьләрен укыгыз әле, – диде ул, яшьләренә тыгылып.

Кадрия Алиш шигырьләрен укыганда Сәрвәр Мусаның дәфтәрен карап утырды.

– Кызлар, карагыз әле, соңгы битендә Муса үзе белән бергә төрмәдә утырган татар егетләренең исемнәрен язган. Монда унике исем. Уникенчесен хыянәтче дигән. Хыянәтчесен дә утыртканнар микәнни?

– Алиш блокнотында да бар ул исемнәр, – диде шунда Кадрия. – Менә, соңгы биттәге «Тормыштан хроникалар» дигән язмасында. Шул ук кешеләр. Ахырдан «Тагын башка байтак егетләр, фамилияләрен белмим» дип бетергән. Сатлыкҗанның да исемен күрсәтмәгән. Унике шигыре бар Алишның. Язарга кәгазе булмаганмы инде?..

– Аның каравы Мусаның шигырьләре күп. «115 шигырем бар. Бу дәфтәргә алтмышын гына күчерәм», дигән. Дәфтәрендә 128 бит. – Сәрвәр тоткыннарның исемнәрен укып чыкты да, – Оркыя, дустым, монда Алишка багышлап язган шигыре дә бар бугай Мусаның, – дип, дәфтәрнең артыннан берничә битне актарып, бер шигырьгә тукталды. – Менә, «Дуска» дигән дә, «А.А.» дип куйган. Исемлектә А.А. хәрефләренә башланган кеше бер генә – Абдулла Алиш.

Сәрвәр шигырьне укый да башлады. Бар да тын калып, аны тыңлады.

Дуска
Абдулла Алишка

Кайгырма, дус, яшьли үләбез, дип,
Без алмадык сатып гомерне.
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?
Билгеләмни гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер...

Сәрвәр шактый озын гына шигырьне бер тында укып чыкты.

– Гениально! – дип куйды Кадрия.

Хатыннарның барысының да күзләрендә яшь иде.

Хатыннар Мусаның шигырьләрен берсен икенчесе алмаштырып укыды. Һәр шигырь саен әлеге шул «Гениально!» сүзен кабатладылар, һәр шигырь саен сыктап алдылар. Шактый озак утырды алар бу кичне. Күптән болай утырышканнары юк иде. Һәркайсы яше белән үзенең хәсрәтен агызды. Арада Оркыя шикелле үк кайгырган хатын Кадрия иде. Фатих Кәрим хатыны. Сугыш менә бетә, менә бетә, шатлыклы очрашу сәгатьләре якынлаша дип яшәгәндә, Кинегсбергны азат иткәндә һәлак булды бит аның Фатихы. Ул да ике бала белән торып калды.

– Кызлар, озак утырдык, таралышырга вакыт, – диде шунда Кадрия, стенада эленеп торган күкеле сәгатьнең күкесе тәрәзәсеннән ун тапкыр күкелдәп алгач. – Нишләтәсең инде син бу шигырьләрне?

– Нишләтсен, Язучылар союзына илтеп бирергә кирәк, – диде Сәрвәр. – Акласыннар исемнәрен. Нинди халык дошманнары булсын ди алар?! Нинди шигырьләр язганнар! Җәлилнекеләр аеруча көчле! Туган илне сөю, дошманга каршы нәфрәт белән язылган. Иртәгә үк тот та илтеп бир.

Хатыннарны озатканнан соң да Оркыя тиз генә йокларга ятмады. Улларына урын җәйде дә, икенче бүлмәгә чыгып, сукыр лампа яктысында шигырь укып утырды. Ул төнне гомумән дә йоклый алмады хатын. Шигырь укыганда туган уйлар аны еракта калган яшьлек елларына, Алиш белән танышып, яратышып, тормыш корып җибәргән, уллары туган, гомерләренең иң бәхетле чорларына алып кайтты.

2.

Эштән соң дус кызлары белән Бауман урамындагы «Унион» кинотеатрына кино карарга барып, аннан соң гына кайтып кергән Оркыяны әнисе:

– Сөенче! Сиңа бер егеттән хат бар! – дип каршы алды.

«Алиштан!» дигән шатлыклы уй яктыртып үтте аның күңелен. Очрашып йөргән көннәрендә үзен әлләни исе китмәгәндәй тотса да, ун көн күрмичә торгач, ул аны юксына башлаган иде. Язучылар союзын оештыру съездыннан соң әле союз әгъзалары итеп алынмаган ике Абдулланы – Абдулла Алиш белән Абдулла Әхмәтне, Идрис Туктар атлы язучыга иярттеп, Ютазы районына әдәби командировкага чыгарып җибәргәннәр иде. Кызлар арасында Абдулла Алишның яшьрәк чакта, әле Җир төзү техникумында укыган вакытларында Кадрия исемле кызга гашыйк булып йөргәнлеге турында сөйләнәләр иде. Чындырмы бу, ялгандырмы, Кадрия Ишукова атлы ул кыз бүген – Алишның Агылый белән Тагылый кебек җан дусты Фатих Кәримнең хатыны. Икесе бер кыз артыннан йөрмәгәннәрдер инде. Белмәссең тагын, алар өчесе дә техникумда бергә укыган. Кайсы кайсын яраткандыр, ә менә дуслыклары һаман дәвам итә.

Оркыя хатны алды да, үз бүлмәсенә кереп, киемнәрен дә алыштырып тормыйча караватына ятты да, конвертын ертып, укырга да кереште.

«Кадерлем Оркыя!

Сиңа Татарстанның иң ерак көнчыгыш чикләреннән сагынычлы кайнар сәламнәр җибәреп, дустың Алиш. Күрешмәгәнебезгә әле бер атна гына вакыт узса да өзелеп сагындым үзеңне. Шушы бер атна гына вакыт та бер ел узган шикелле бик озак булып тоела. Аңлыйм, без инде борыннарына мәхәббәт исе әле кичә генә керә башлагын унҗиде яшьлек бала-чагалар түгел. Дөрес, синдә горурлык, зурлык бераз бар, миндә, бәлки, татарлык бардыр. Ул бит личность кимчелексез булмый. Шул кимчелекләр арасыннан сайлап алып, яхшы якларны күрә белү зур эш... Минемчә, безнең характерлар арасында алай бик нык аерымлык, каршы килүчелек юк. Һәрхәлдә, андый эшләр булса да, бер якның ташлама ясавы белән, ул тигезләнәчәк...»

(Дәвамы киләсе санда).

Йолдызсыз калган 25 татар каһарманы

ЗИННӘТУЛЛИН ӘСХӘТ ЗИННӘТУЛЛА УЛЫ

Зиннәтуллин Әсхәт Зиннәтулла улы – 1922 елгы, Кызыл Йолдыз (Котлы Бүкәш) хәрби комиссариаты аша сугышка озатылган. 186 нчы укчы дивизиянең 238 нче укчы полкында хезмәт итә, капитан дәрәҗәсенә ирешә. Яулар барышындагы батырлыгы өчен өч мәртәбә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1945 елның 15 маенда аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. Татар улының каһарманлыгы Александр Невский ордены белән генә бәяләнә.

Әсхәт Зиннәтуллинны Герой исеменә тәкъдим итү рапорты.



8Х06491
25.5.45
185

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество: ЗИННАТУЛЛИН Асхат Зиннатуллинович
2. Звание: капитан 3. Должность: Командир стрелковой роты 238 стрелкового Гдыньского полка 186 стрелковой Брестской Краснознаменной дивизии
Представляется к званию "ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА"
4. Год рождения: 1922 5. Национальность: Татарин 6. Партийность: чл. ВКПб-44г. №6313739
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне: Участник Отеч. войны с 05-42г. Калининский, Брянский, 1 и 2 Белорусские фронты.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне: Конт. 3-10-44, ранен легко 17-2-45г
9. С какого времени в Красной Армии: с Мая 1942 года
10. Каким РВК призван: Призван Кзыл-Юльским РВК Тат. АССР.
11. Чем ранее награжден: Ор. Отечественная война 2 ст. Пр.3 арм. 304/н 15-7-44 Ор. Красная Звезда Пр. 186 Сд № 029/н 30-10-43
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

Тов. Зиннатуллин А.З. в боях при форсировании реки Одер с преодолением утопающих болот с 18 по 22-4-45 проявил образцы смелости в управлении боем.

Несмотря на ураганный огонь противника, он своим личным примером бесстрашия, увлекая бойцов на разгром противника. Тов. Зиннатуллин не щадя своей жизни на лодках переправлял бойцов, материальную часть и с хода контратаковал врага-завязав бои на улице населенного пункта, а в последствии овладел им. Противник упорно сопротивляясь бросался в яростные контратаки.

Тов. Зиннатуллин находясь вместе со стрелками своим примером храбрости с криками "ура" поднял подразделения в атаку и опрокинул врага. Бойцы видя своего бесстрашного командира впереди, с удвоенной энергией шли на противника и разгромили его.

В этих боях рота под командованием тов. Зиннатуллина истребила 110 немцев и уничтожила 4 станковых пулемета и одну противотанковую пушку.

За мужество и отвагу проявленные в боях, тов. Зиннатуллин А.З достоин присвоения звания "ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА"

КОМАНДИР 238 СПП
гв. подполковник /...гнов/

"15" Мая 1945 года.

МОСТАФИН СӘЕТ НИГЪМӘТҖАН УЛЫ

Мостафин Сәет Нигъмәтҗан улы – 1918 елда Казанда туган, Буа район комиссариаты аша фронтка озатылган. Кызыл байраклы 367 нче бомбардировка авиация полкында эскадрилья командиры, капитан. 1945 елның 25 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, 3 нче дәрәҗә Суворов ордены белән генә бүләкләнә.

НУРЕТДИНОВ ГАБДУЛЛА ФӘХРИ УЛЫ

Нуретдинов Габдулла Фәхри улы – 1925 елгы, Балык Бистәсе район комиссариаты аша чакырылган. 295 нче укчы дивизиянең 1042 нче полкында укчы-мәргән, рядовой. 1945 елның 30 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, 1945 елның 4 июнендә Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

РӘХМӘТУЛЛИН ХӘБИБУЛЛА ИБРАҺИМ УЛЫ

Рәхмәтуллин Хәбибулла Ибраһим улы – 1912 елда Әгерҗе районының Нарат авылында туган, Красный Бор район комиссариаты аша чакырылган. 1 нче Белоруссия фронтындагы 2 нче танк армиясенең Кызыл байраклы Умань мотоукчы бригадасында 3 нче батальон командиры булып яу йөри, майор. 1944 елның 14 августында Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

ИБРАҺИМОВ ГАБДУЛЛА ГАБДРАХМАН УЛЫ

Ибраһимов Габдулла Габдрахман улы – 1925 елгы, Дөбъяз хәрби комиссариаты аша мобилизацияләнгән. Ерак Көнчыгыш фронтындагы 5 нче армия составындагы 144 нче укчы дивизиянең 785 нче укчы полкында укчы кызылармияче булып хезмәт итә. 1945 елның 30 августында аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр, әмма штаб түрәләре татар егетенең батырлыгын Кызыл Байрак ордены белән генә бәяли.

Г.Ибраһимовны Герой исеменә тәкъдим итү кәгазе.



25.к
Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ
194

1. Фамилия, имя, отчество ИБРАГИМОВ АБДУЛ ГАБДРАХМАНОВИЧ
2. Звание Красноармеец 3. Должность, часть Стрелок 785 стрелкового Краснознаменного полка 144 стрелковой дивизии
Представляется к награде званию ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА
4. Год рождения 1925г. 5. Национальность татарин 6. Партийность беспартийный
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР в Отечественной войне (где, когда) В Отечественной войне с 06.1943г.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне Три тяжелых ранения: 8.9.43г Спасск-Деменск, 10.10.44г. Литва, 2.2.45г. Вост. Пруссия. Легко ранен 12.4.45г. Восточная Пруссия
9. С какого времени в Красной Армии 1943г. 10. Каким РВК призван Дубьязовским РВК, Татарской АССР
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Наград не имеет
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи
13. Удостоверение личности, серия №

1. Краткое конкретное изложение боевого подвига или заслуг

Во время прорыва японских укреплений на границе с Маньчжурией 9 августа 1945г. (Ново-Алексеевка, Гродековского района) тов. Ибрагимов действуя в составе штурмовой группы, одним из первых достиг высоты 614,1 и забросал гранатами основной ДЗОТ, мешавший продвижению роты, уничтожив при этом 12 японских солдат и офицеров-этим обеспечил выход роты на гребень высоты и овладение последней.

В бою восточнее Мациохе 10.8.1945г. наступая на высоту, где закрепились японские "смертники"-взвод встретил сильный пулеметный и оружейный огонь противника. Товарищ Ибрагимов, пользуясь кустарником и выгодными складками местности, вышел в тыл японцам и с криком "взвод за мной, вперед за Родину" начал забрасывать японцев гранатами-последние решив, что попали в полное окружение беспорядочно бежали и были истреблены нашими бойцами.

В бою за высоту 449,1 товарищ Ибрагимов в рукопашной схватке уничтожил 3 японских "смертников" и одним из первых достиг вершины высоты.

При форсировании реки Муданьцзян 16.8.1945г. Ибрагимов с группой 3-х человек, используя подручные средства, первым переправился на западный берег реки и вступил в бой с группами прикрытия японцев, чем дал возможность переправы своему подразделению и содействовал выполнению боевой задачи по овладению города.

Достоин присвоения звания ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

Командир 785 стр. Краснознаменного полка
Подполковник /МЕРКУЛОВ/

"30" августа 1945г.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.

Тинчурин театры тарихы белән артист Исламия Мәхмүтова бер-берсеннән аерылгысыз сыман. Сәхнәгә ул 19 яшендә махсус белем алмыйча килеп керсә дә, тора-бара «күчмә театрның әнисе» исеменә лаек була. Тормыш иптәше Хәлил Мәхмүтов белән кавышкач, Исламия ханым исеме сәнгать күгендә җетерәк яна башлый. Шушы театрда сәнгатьтә беренче адымнарын ясаган кызлары Лилия белән Ләйсән дә, кияүләре Ринат Шәмсетдинов та Исламия ханымның дәрәҗәсен-данын арттыра. Мәхмүтовлар династиясе барлыкка килә. Тамашачы спектакльгә билет алганда, Мәхмүтовлар уйныймы, дип кызыксына башлый...

Көрәшче рухлы

Үзе арабызда булмаса да, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты И.Мәхмүтованың исеме бүген дә халык күңелендә яши. Аның 80 еллыгы театрның 90 еллыгына туры килү дә очраклы түгел сыман.

Исламия Мәхмүтова – бәхетле артистка. Аның иҗат бакчасында К.Тинчурин, Н.Фәттах, Ш.Камал, Җ.Фәйзи, М.Кәрим, Т.Миңнуллин, Т.Гыйззәт. М.Мәһдиев, И.Юзеев һ.б. классикларыбызның үлемсез әсәрләре бар. Шулар янында К.Гольдони, В.Шекспир, Б.Брехт, М.Горький һәм дөнья күләмендә танылган бүтән драматургларның пьесалары да җитәрлек. Күп очракта спектакльләрнең уңышы анда катнашкан Исламия Һидиятулла кызының осталыгына барып тоташа. Илдар Юзеевнең «Кыр казлары артыннан» әсәрен генә мисалга китерик. Ул 1976 елда куела, әмма анда яңгыраган шул ук исемдәге җырны бүген дә тамашачы сәхнәләрдә көтеп ала, аның беренче ноталарын ишетүгә үк шатланып кул чаба башлый. Кызганыч, җырны Исламия апабыз кебек башкаручылар гына юк. Гомумән, драма артистлары җырларны эстрада җырчыларына караганда да үтемлерәк итеп башкара кебек. «Әсәремнең шулай озын гомерле булуы, һичшиксез, Исламия Мәхмүтованың талантлы башкаруына бәйләнгән», – дия торган булган Илдар Юзеев үзе дә.

Мәхмүтова илле елдан артык гомерен татар театрына багышлады. Шуның яртысы тәгәрмәч өстендә, халык арасында үткәнгәме, аның иҗаты халыкчан, күңелгә якын, теле татлы иде. Шул халыкчанлыгы белән Исламия апа күпләргә театр сөючеләрнең йөрәгенә юл тапты.

Тамашачыны актрисаның гаҗәеп көчле энергиясе, темпераменты да үзенә тарткандыр. Аның сәхнәне тутырып килеп чыгулары әле дә күз алдында тора. Лирик җырларны эреп китәрлек итеп башкарса да, көрәшчеләр рухыннан иде Исламия ханым. Көрәшеп, Тинчурин театрына бина яулап алган шәхес ул. Камал театры Горький урамыннан Татарстан урамындагы хәзерге биналарына күчкәч, алты артист – Исламия Мәхмүтова, Марсель Җаббаров, Айзирә Мотаһарова, Әнәс Галиуллин, Ринат Мифтахов, Гөлчирә Закирова Мәскәүгә, СССР Мәдәният министрлыгына юл тота. Ниятләре – күчмә театрны Спас манарасындагы түбәсе җимерелеп килгән бүлмәдән зур, якты, иркен бинага күчерү. Ильичева атлы ханымга бөтен зарларын сөйлиләр, татар театрының мәһабәт бинага лаек булуын мең кат дәлилләр. Ильичева тыңлый-тыңлый туеп-арып бетә. Моңа кадәр үз күзе белән күргәне булмаса да, татар театрының, чыннан да, антик чордагыдай зур сарайларга лаек булуына ышана башлый. Чөнки казанлылар җыйнаулашып килгән. Гадәттә, артистлар берәм-берәм, фатир, лаеклы исем, грамота сорарга килә. Ильичева Исламия ханымның ялкынланып сөйләвенә бигрәк тә гашыйк булган, ахры. Казанга кайтуларына, боларны

үзебезнең Мәдәният министрлыгында көтеп торалар. Һәм тиз арада биналы да булып куялар. Шулай итеп, Тинчурин театрының күчмә тормышына нокта куела. Хәер, озын-озак гастрольләр аннан соң да дәвам итә әле....

Халык арасында спектакльләр белән йөргәндә нинди генә язмышларга дучар булмыйлар да, нинди генә җан өшеткеч тарихлар ишетмиләр. Сизгер җанлы И.Мәхмүтова шуларны барысын да мыегына чорнап бара. Һәм бер көнне үзе дә яза башлый. Әфганда һәлак булган дип саналган, әмма ахырда исән-имин кайтып кергән егет турында «Син бит минем бергенәм» пьесасы 1997 елда языла. Аннары «Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде» иҗат ителә. Өчесе дә тормыштан алынган. Бу әсәрләрнең язмышы бәхетле булып чыга. Тормышчан пьесаларны актриса күңел самимилеген кушып сәхнәләштерә һәм алар озак еллар сәхнәләрдә уйнала. Бүген дә тамашачылар Исламия Мәхмүтованы һәм яшьлекләрен сагынып, бу спектакльләргә зал тутырып килә.

Язучылар төрле була. Бөтенесе дә сюжетны тормыштан алырга омтыла. Әмма ни өчендер барыбер әсәрләр аерыла. Моның сере нидә? Әле күптән түгел генә М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт драма театры гастрольгә Казаныбызга килгәч тә шул турында күп уйланылды. Ник дигәндә, бу килүләрендә бик төрле спектакльләр алып килгәннәр иде. Җәмгысы ун әсәр. Милли фольклорга нигезләнгән «Кодача» музыкаль комедиясе аеруча хуш килде. «Җиде буын» шәлкеменнән милли телнең киләчәге турында борчылып куелган һәм бик көчле яңгырашлы ике спектакль шулай ук йөрәкләргә үтеп керде. Башкортстанда туган һәм «Кызыл паша» исеме белән билгеле татар кешесе Кәрим Хакимовның дипломат буларак Якын Көнчыгыш илләре белән дуслык урнаштыруы, 1938 елда исә атып үтерелүе турында спектакль дә күңелдә байтак сораулар уятты. Нишләп моны башкортлар куярга батырчылык иткән, ә без түгел? Халисә Мөдәррисова әсәре буенча куелган «Бәхет хакы» спектаклендә атаклы Фидан Гаффаров сәхнәгә чыкты, ул да онытылмаслык. Ләкин арада бөтенләй бүтән ике спектакльнең булуы бераз кәефне кырды. Дөрес, алар икесе дә шәп куелган. Халык та бик яратты. Мышык-мышык борын тартуларына караганда, күңелләре бик нечкәргән иде. Зифа Кадыйрова әсәре буенча куелган «Синсез килгән язлар»да ирләренең хыянәтеннән соң озак кына күңел җәфалары кичергән яшь һәм олы яшьтәге ике хатын-кыз язмышы сурәтләнә. Заһидә Мусина романы буенча сәхнәләштергән «Килен» тамашасында исә вакыйгалар башта анасы, аннары кайнанасы, ире тарафыннан җәберләнеп, ахыр чиктә ялгыз калса да, бәхетле булырга үзендә көч тапкан яшь хатын тирәсендә әйләнә. Вакыйгаларның телевидение экраннарында көн саен әйләндерелгән очсызлы хатын-кыз сериалларындагы ише гади, затсыз икәнен дә аңлыйсың. Әмма артистлар уены шулкадәр җәлеп итә ки, теләсәң-теләмәсәң дә ахыргача карап бетерәсең. Академия театры артистлары уйный бит. Халык ярата, кул чабып геройларны хуплый. Бу әсәрнең кыйммәте нидән гыйбарәт, дигән сорау берәүдә дә тумый. Биш-алты көнлек гастроль программасында ике шундый тамашаның булуы артыграктыр, бәлки. Академия театрлары халыкны җиңел җәлеп итә торган, бер күзәнәкле әсәрләр кую ягына борылган, дигән сүзме бу? Тамашачының мышык-мышык җебеп утыруына үзләре дә алданамы артистлар? Халык ярата икән, димәк, без дөрес юлда, диме? Академия театрында куелгач, артистлар бирелеп уйнагач, тамашачының бер карап онытыла торган спектакльләрне эталон дип кабул итми хәлләре юк...

Исламия Мәхмүтованың пьесалары да гади, фәлсәфәле уйларга этәрми кебек. Әмма бу ике төр әсәрләр барыбер нәрсәсе беләндер аерыла. Ул аерманы эзләп озак баш ватасы түгел – поэтика, безнеңчә әйтсәк, шигъри аһәңдер ул, могаен. Мәхмүтова тормыштан алып язса да, барыбер символлар белән эш итә – мәхәббәт чишмәсе, мәсәлән. Мәңгелек темалар күтәрә – әйтик, сугыш. Һәр чорда да кыйммәтле булган игелек, миһербанлык кебек төшенчәләрне алга сөрә, әйтик, тәрбиягә алынган бала. Кайбер авторлар кебек, ире кыйнаган хатынны пьедесталга күтәрергә маташмый. Чөнки сәхнә ул тормыш үзе түгел, аның чагылышы, дигән бер классигыбыз. Кыйналган хатыннардан кала сәхнәгә күтәрердәй бүтән геройларыбыз да бар, мәсәлән, шул ук «Кызыл паша»...

Исламия апабызның бөтен талантларын санап бетермәгәнбездер әле. Мәсәлән, аның режиссер буларак Д.Салиховның «Яшьлек хатам – йөрәк ярам», И.Юзеев-

Исламия ханым

нең «Резидәкәй», Н.Гаетбайның «Аты барның дәрте бар», Р.Сәгъдинең «Сынган беләзек» пьесаларын сәхнәләштерүен әйтергә онытканбыз.

Ә иң зур эшләренең берсе – Б.Брехт пьесасы буенча куелган «Кураж ана» спектаклендә Кураж ана роле турында аерым әйтү кирәк. Беренчедән, актриса бу әсәрне үзе татар теленә тәрҗемә итте. Аталарын, бабаларын сугышта югалткан татар тамашачысына якын булсын, дип тырышып эшләде. Әсәре дә нинди бит! Драматург аны Бөек Ватан сугышы алдыннан, 1939 елда язып тәмамлаган һәм соңга калуына бик уфтанган. «Язучылар, ил башлыклары сугыш башлаган тизлектә яза алмый, чөнки язу өчен баш кирәк», – дип теркәп куйган ул көндәлегенә. Вакыйгалар Германиядә бара, анда исә утыз ел дәвам иткән сугыш милли афәткә китерә. Баш героиня сугыштан файда күрә, ахыр чиктә шул канкоешта балаларын югалта. Чынлыкта, Кураж ана сугыштан арына алмаган, үзен дә, башка халыкларны да юк итүче, акылга утыра белмәгән илне гәүдәләндерә. Сугыштан файда күрүче Кураж ана образы белән автор коммерция максатларын күз уңында тотучы ил башлыкларына киная ясаган. Автор бу пьесасын халыкларны кисәтер өчен язган була. Әмма, күргәнебезчә, кешелек акылга килә белми. Кызганыч, бүген «Кураж ана» спектакле сәхнәләребездә бармый. Исламия апабыз бу рольне татар кешесенең йөрәгенә үтәрлек итеп башкарган иде. Бүген дә бәрелеш кырларында асыл улларыбыз баш сала бит...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
1 декабрь
№47, 2023

МИНЕМ

(Дәвамы. Башы 46 нчы санда).

1975 елда В.Хомяковны Монголиягә чакыралар. Сигез ай буе шул илдә тимер рудасы эзли. Ял вакытларында күпсанлы экспедицияләрдә катнашып, бөтен Советлар Союзын әйләнеп чыга: Ерак Көнчыгыш, Себер, Свердловск, Чиләбе өлкәләре, Казахстан, Карелия, Балтыйк буе республикалары... Африка чүлләренә хәтле барып җитә ул...

1977 елда, табиблар киңәше белән, Виктор Афанасьевич металлурглар шәһәрен Чаллыга, автомобиль төзүчеләр каласына алмаштыра. Сәламәтлеге нинди булуга карамастан, Герой кул кушырып утырырга уйламый да. 1980 елда Кою заводының җылылык белән тәэмин итү һәм вентиляция цехына слесарь-ремонтчы булып урнаша.

Ике югары белеме була торып та, аны, ни гаҗәп, иң түбән – өченче разряд белән генә кабул итәләр. Квалификациясен күтәрү турында сүз кузгалса, тәҗрибәле белгечкә һөнәри курсларда укып чыгарга киңәш ителәр. Ялга китәр алдыннан шелтә дә эләктерә әле Герой. «Унөченче» хезмәт хакыннан мәхрүм итәләр. Чынлыкта, ике смена рәттән эшләгән В.Хомяковка икенче көнне мастер ял бирергә тиеш була, ләкин «оныта». Нәтиҗәдә, «прогул» чәпиләр...

* * *

Виктор Афанасьевич белән без Чаллы шәһәр тарихы музееның күргәзмә залында очраштык. Ярым хәрби киемдә, күкрәгенә орден-медальләр планкасы таккан, кулында таяк, уң аягы сизелерлек аксый. Игътибарны шундук үзенә җәлеп итте.

– Кем сез? Кайдан килдегез? Бу нинди бүләкләр?...

Сорау арты сорау яудырабыз. Иң әүвәл яңа танышыбыз Советлар Союзы Героеның «Алтын Йолдыз» медаленә тукталды.... Башта аның кыйссасына ышанмадык. Тиз генә ышанырлык идемени соң – каршыбызда чып-чын Герой басып торсын әле! Тормышы, хезмәт юлы белән кызыксына башладык. Үзе белән аучылык билеты, Жуков медале таныклыгының күчерелмәсеннән башка документлары юк иде аның.

Советлар Союзы Герое исеме бирелү турындагы СССР Югары Советы Президиумы тапшырган Мактау грамотасын, башка документларын туган ягына – Магнитогорскига җибәргән икән. Чөнки исәбе – бөтенләйгә шунда кайтып китү. Үз фатирын алмаштырган да инде. Хәзерге көндә хатыны Зоя Анатольевна Хомякова-Лаптева торагында яши...

– Димәк, Герой буларак, «зур» пенсия түләмиләр? – дип кызыксынабыз.

– Әлегә рәхәтләндергәннәре юк. Һаман җыенып бетә алмыйм, хәрби хезмәттә имгәнгән аяк җибәрми...

– Нишләп соң Советлар Союзы Герое исеменә лаек булуыгыз турында Чаллы халкы әлегә хәтле белми килде? Беркайда язып та чыкмадылар кебек...

– Нишләп, шәһәрдә дә белделәр. Беренче тапкыр полковник формасын һәм «Алтын Йолдыз»ны 2001 елда, Җиңү бәйрәмендә кигән идем. Ул вакыттагы шәһәр хакиме Рәшит Хәмәдиев шундук игътибар итте. Тантана вакытында яныма килеп, озак кына түшемдәге орден-медальләргә карап торды.

– Мондый бүләкләрне тагып йөрү өчен лаеклы булырга кирәк, абзый, – диде, «Алтын Йолдыз» медаленә ишарәләп.

– Бары да тәртиптә, – мәйтәм, түш кесәсеннән документларны алып күрсәтеп...

Рәшит Хәмәдиевнең беренче очрашуда миңа ышанмыйча каравын аңларга була, билгеле. Бүгенге армия, хәрби сферадагы башбаштаклык, «бардак» турында ул да белгәндер. Бәлки... Шундый көнгә килеп җиттек бит, кемнең кем икәнен, нинди лаеклы гамәлләре булуын карап тормастан, полковник, генерал дәрәҗәләре бирелә. Югары хәрби структурада да ришвәтчелек, туганлык-ахирәтлек чәчәк атты. Хәзерге вакытта ни генә әйтмәсеннәр, мәсәлән, полковник дәрәҗәсенә ирешү өчен гаять зур гамәлләр кылырга, яки академия тәмамлаганнан соң да озак еллар хезмәт итәргә кирәк бит әле ул. Димәк, артык тир түкмичә генә бу погоннарны алу өчен офицерлар башка юллар табарга тиеш була. Андый псевдокомандирлар белән тулган армиянең бүгенге сыйфатын да, киләчәген дә күзаллавы кыен түгел...

Шәһәр хакиме бүләк тарихы белән кызыксынды, үз янына чакырды. Аның эш бүлмәсендә әңгәмә вакытында аңа үз тормышым, хезмәтем турында җентекләп сөйләдем. Ул миңа шәһәр хәрби комиссариатында һәм социаль яклау органнарында Герой буларак исәпкә басарга тәкъдим итте. Ләкин мин, тиздән туган ягыма кайтып китәчәгемне сылтау итеп, аның тәкъдимен кире кактым. Икенче елны Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларга тиңләштерелгәннәр белән Кою заводында очрашу вакытында шәһәр хакимияте вәкиле миңа исемле бүләк – «Советлар Союзы Герое В.А. Хомяковка шәһәр хакимияте башлыгыннан» дип язылган фотоаппарат тапшырды. Ни кызганыч, аппарат эшкә яраксыз булып чыкты. Аны яңасына алмаштырырга туры килде. Бүләкнең бүген кайда, кем кулында икәнлеген дә белмим. Мохтаҗлык мине шәһәр тарихы музеена да китерде. Магнитогорск металлургия комбинатының Новинка ярдәмчел хуҗалыгында эшләгән чорда, сейфы-ние белән, бик оригиналь, өч көпшәле ау мылтыгымны урладылар. Тула корал заводында эшләнгән бу мылтыкны Монголиядә вакытта алган идем. Совхоз тракторчысы Смирнов әйтүенә караганда, ул шул ук авылда, бер күзле Клавдия исемле хатын йортында күренгән. Аның турында башка мәгълүматларым юк. Үзем дә, музей җитәкчелеге дә берничә мәртәбә хокук саклау органнарына хат язып карадык. Нәтиҗәсе генә булмады.

Бүгенге армия, командование турындагы сүзгә кире кайтып:

– Татарлар арасында дусларым күп булды, дисез. Өлкән офицерлар арасында татарлар бар идеме? – дигән сорау бирдек. – Гади халык һич тә аңлый алмый торган хакыйкать – «югары эшелон»га татарларны бик теләп үткәрмәгәннәр, бүген дә үткәрмиләр, диярлек...

– Татарлар, сирәк булса да, очрады, – диде Виктор Афанасьевич. – Гомумән, безнең чорда армиягә интернациональлек дигән күркәм сыйфат хас иде әле. Бик яхшы танышым бар иде. Полковник. ГАИ башлыгы. Әле үзе постта торган чакларында да, җитәкче булгач та, кешеләргә карата мәрхәмәтле булырга тырышты. Ул җитәкче булып эшләгәндә юл йөрү кагыйдәләрен бозу очракларының бермә-бер кимүе, бер генә кешенең дә машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителмәве күп нәрсә турында әйтә торгандыр. Әйе, татарлар – кешелекле, тырыш халык...

...1991 елда, СССР Хәрби Көчләренең ветераннар советы һәм элекке нәни концлагерь тоткыннары берлеге башлангычы белән Германиягә сәяхәт оештырыла. Анда катнашучылар арасында Татарстаннан да 8 кеше була. Икесе – Чаллы

ОЧАСЫМ КИЛӘ...

шәһәреннән. Сәяхәт алдыннан, билгеле, документлар бик җентекләп тикшерелә. КамАЗның ул чагындагы Ветераннар советы рәисе Виктор Сычев, В.Хомяков документлары белән беренче тапкыр танышып чыккач та, югалып кала.

– Нәрсә күрсәтәсең миңа, иптәш Хомяков? – ди рәис. – Тотып ат... бәдрәфкә.

Соравы нинди – җавабы шундый:

– Бәдрәфтән үз кулларың белән алырга туры килмәгәе!..

Америка оккупацион зонасында комендатура тарафыннан бирелгән нимес телендәге таныклыкларны КамАЗ тәрҗемәчеләре урысчага күчерә. Документлар КамАЗның генераль директоры Николай Бех кулына килеп ирешә. Мәскәүгә кадәр бөтен Татарстан делегациясе КамАЗ берләшмәсе самолетында оча. Башкалада ветераннар Освенцим, Дахау концлагерена һәм Мюнхенга баручы төркемнәргә бүленә.

«Элекке тоткыннар концлагерь михнәтләрен кабаттан кичергәндәй булды, – дип искә ала Виктор Афанасьевич. – Сәяхәтне оештыручылар да моны яхшы аңлады, без газап чиккән концлагерьларны читтәнрәк әйләнеп үтәргә тырыштылар. Күзләр тәрәзәдә, юл читеннән 1-2 чакрым гына ераклыктагы концлагерь тарафында. Ә Мюнхенда безне крематорийга алып керделәр... Күпчелегенең сәламәтлеге какшады, Германия хастаханәсендә ятып калырга мәҗбүр булдылар. Туган илгә авырлык белән генә кайтып егылдык ул чакта...»

Россия хөкүмәте һәм Германия арасындагы килешү буенча, нәни тоткын исәбенә кертелгәннәр, шул исәптән, В.Хомяков та, бер ел буе, аена 8 мең марка күләмендә компенсация түләве алырга тиеш булган. Тик бу акчаның бер өлешен генә биргәннәр. «Промстройбанк» дигәне, Германиядән күчерелгән акчаны үзләштереп, «банкротлыкка» чыккан. Бу башбаштаклыкка нәфрәтләнгән Германия ягы безнең шәһәргә бер-бер артлы хатлар яудырган. Тик алар җавапсыз калган...

Бу вакыйгалардан соң Виктор Афанасьевич шул ук елны үз куллары белән документларын шәһәр башкарма комитетының социаль-тәэминат бүлегенә илтеп тапшыра. Исәбе – хәрби пенсия алу. Документлар... гөнаһ шомлыгы, каядыр югала. Чираттагы очрашу вакытында, бюрократия галәмәтенә чыдамлыгы калмаган Герой, өстәлдә яткан иске «чут»ны алып, бүлекнең бер хезмәткәренә томыра. Тидерә алмаганына әле дә үкенә. 5-6 елга сузылган эзләнүләр, төрле даирәләргә мөрәҗәгать итүләр бернинди нәтиҗә бирми. Дөресрәге, моның нәтиҗәсе – тагын да ныграк какшаган нерв системасы, беткән сәламәтлек... Аптыраштан калган Герой 2005 елның кышында, үз кулы белән язып, Россия Президентына хат юллый. Президент администрациясе идарәсеннән менә мондый җавап килеп төшә:

«№ А26-09-56154 от 15/03/2005 года. Хомякову В.А.

Сообщаем, что Ваше обращение, поступившее на имя Президента РФ, направлено на рассмотрение в Кабинет Министров Республики Татарстан.

Консультант департамента письменных сообщений граждан А.Ягодкин».

Виктор Афанасьевичның үтенече, Татарстан хөкүмәтенә юлланып, соңыннан ачыкланганча, тәгәллек кертү өчен Чаллы шәһәре хакимиятенә җибәрелгән. Ләкин Геройга бер генә җавап та килеп ирешмәгән!..

Күргән михнәтләре, газаплары турында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә да сөйләп биргән ул.

«Чираттагы Сабан туе бәйрәмендә ат чабышы карарга барган идем. Уйланып торганда, арттан килеп, кемдер җилкәмә кагылды. Борылып карасам – Президент! Борчу-мәшәкатьләрем хакында аңа бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем...»

Нык ихтирам иткән ул Минтимер Шаймиевне. Шуңа күрә гаделлек хакимлек итәчәгенә бүгенгәчә өметен өзмәгән...

Сәламәтлеге какшаса да, Виктор Афанасьевич кабат самолет штурвалы артына утыру хыялы белән яши. Әле Магнитогорскида яшәгәндә үк параплан ясаган: канатлары – җилкән материалыннан, ике тупсалы редуктор көйләнгән двигателе - «Днепр» мотоциклыныкы. Очу аппараты тиешле даирәләрдә рәсми теркәлгән. Очучы үзе исә аны идарә итүгә хокук алган. Параплаңга яраклы тәгәрмәчләр булмау сәбәпле, аппарат 8 еллап гаражда яткан. Тәгәрмәчләрне, ниһаять, Түбән Камадан юнәтә алган Герой. 90 нчы еллар азагында беренче тапкыр 15 минутлап очкан да әле – Әлмәт шәһәренә барган һәм кире әйләнеп кайткан.

– Бу сәяхәт «Татнефть» акционерлар җәмгыяте генераль директоры Шәфәгать Тәхаутдинов чакыруы буенча оештырылган иде, – диде Виктор Афанасьевич. – Сакчылары, күрер күзгә сәер очкычны шәйләп алгач, ут ачты. Канатлар сафтан чыкты. Могҗиза белән генә очкычымны бер коттедж янындагы асфальт юлга утыртә алдым...

Әңгәмәбез азагында гадәти сорау бирдек:

– Хәзер нинди планнар белән янасыз инде?

– Аякны савыктырып, очучы буларак янә самолетка утыру. Яки, һич югы, үземнең параплан белән Магнитогорскига кадәр очарга исәп, – диде хыялый Герой, күзен очкынландырып...

P.S. Гаеп, димәсәк тә, житешсезлегебез инде бу – Чаллы шәһәрендә бүгенге көндә каһарман шәхес, шәп кеше – Советлар Союзы Герое В.А. Хомяков гомер кичергәнлеген моңа кадәр белми йөргәнбез бит! Беренче очрашудан соң шактый сулар аккан. Герой белән кабат очрашып сөйләшергә булдык. Фатирында берүзе иде ул. Еллар үзенекен иткән: каһарман бүген инде авырлык белән генә хәрәкәтләнә, сөйләшә. Чынлап та, гаҗәеп эрудицияле, сәләтле, «аяклы энциклопедия», кызыклы әңгәмәдәш үзе.

Бүген Виктор Афанасьевич бөтенләй караучысыз калган икән. Кайчандыр каршында биеп кенә йөргән медицина хезмәткәрләре дә юкка чыккан. Хәтта укол салдырырга да шифаханәгә үзе бара; улының да ерак-ераклардан сәлам хатлары гына килеп тора; берике мәртәбә килгәләгән шәһәр тарихы музее хезмәткәрләре дә инде юлны оныткан... Ике бүлмәле фатирда берьялгызы җан асрамыш. Коллекциясендәге асылташлар, минераллар да кайсы кая таралып бетә язган: музейларга, элекке дусларына бүләк итеп биргән, бер өлешен апасының улы Магнитогорскига алып киткән. Үзе ясаган очкыч та Магнитогорскида икән инде. Көч-хәл белән генә хәрәкәтләнә Герой, парапланга утыра алмаячагын да аңлагандыр, күрәсең. Бердәнбер дусты, ярдәмчесе – күрше фатирда гомер кичергән бер әби.

– Юк-юк та, ул кереп ашарга пешергәләп чыга, – диде Виктор Афанасьевич. – Аңа рәхмәт инде.

– Ә хакимият?

– Юк, хакимияттән бер генә кешенең дә килеп күренгәне юк. Гомумән, алар мин барлыкны белми дә шикелле тоела. Магнитогорскига кайтып китәргә җыенам, дип тә сөйләнгән идем бит...

Замана, диген. Кечкенәдән әсирлек-коллык газаплары чиккән нәни партизан, кайчандыр кешеләр иминлеге өчен саулыгын югалткан, каһарманлыгы өчен Советлар Союзы Герое исемен алган шәхес бүген беркемгә дә хаҗәт түгел!

Виктор Хомяков, чегән, нимес телләрен яхшы белүе өстенә, татарча да иркен аралаша.

– Дуслар, хезмәттәшләр арасында татар кешесе күп булды, – диде ул. – Якын дуслар телен белмәү аларны хөрмәт итмәү булыр иде, дип уйлыйм...

Билал КАНЕЕВ,
Амур ФӘЛӘХ.
Чаллы.

Редакциядән: Советлар Союзы Герое В.Хомяков, асылда да, Чаллы һәм Татарстан җирендә терәк таба алмады һәм 2000 нче еллар азагында Магнитогорскига кайтып китте. Ни кызганыч, анда да озак гомер итә алмады, мәңгелеккә күчте.

Мари Эл имамнары халыкка хезмәттә

Ут күршебез Мари Эл республикасының Бәрәңге районы – күп кенә татар дин эшлеклеләренең, остаз-мәгърифәтчеләрнең кече ватаны. Бу төбәктән чыккан танылган дин әһелләре – имам Хафизетдин ибн Насретдин әл-Бәрәңгәви, Оренбург мөхтәсибәте дини җыелышы ахуны һәм казые Борһанетдин ибн Насретдин, имамнар Фидай-Мөхәммәд Насретдинов (1869-1924), Зөлкарнәйн Насретдинов (1882-1971), Хәлилрахман Насретдинов (1890-1964) һ.б. берничә гасыр дәвамында Россия күләмендә халкыбызга хезмәт иткән. Бәрәңгелеләр бүген дә динебезне ныгыткан бу данлыклы дин әһелләре белән горурланып яши. Быел бирегә икенче тапкыр «Насретдин укулары» дип аталган фәнни-мәгърифәти конференция узды. Аның беренчесе нигезгә Фидай-Мөхәммәт хәзрәт һәм аның улы Хәлилрахман Насретдиновларга багышланса, быел гыйльми җыен «Мари Эл имамнары халыкка хезмәт итүдә һәм рухи мирасны саклауда» дигән темага үткәрелде. Конференция Россия мөселманнары, Мари Эл мөселманнары Диния нәзарәтләре, Мәскәү ислам институты, Мари Эл мәдәният, матбугат һәм милләтләр эшләре буенча министрлык, Бәрәңге районы хакимияте һәм «Медина» нәшрият йорты ярдәме белән оештырылды. Җыен укытучы һәм остаз елы уңаеннан һәм Санкт-Петербург император университеты лекторы, күренекле мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның тууына 200 ел тулуга туры китереп үткәрелде.

Җыен Марий Эл Республикасының Бәрәңге районы башлыгы Әлфит Ибраевның, Марий Эл Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Фәрит хәзрәт Шаһиевнең сәламләү чыгышлары белән башланды. Ә җыенда күтәрелгән мәсьәләләрнең берсе, әлбәттә, Мари Элдә Ислам диненең торышы иде. Диния нәзарәте рәисе Ф.Шаһиев искәрткәнчә, бу якларга татарлар Казан Явыз Иван тарафыннан яулап алынгач, чукындырудан качып утырган. Араларында иң танылганы Хафизетдин ибн Насретдин. Аның гаиләсендә балалар күп була, нәселе киң тарала.

Бүген Мари Эл мөхтәсибәтендә җиде дини оешма бар. Бәрәңге, Красногорскины, Суслонгерны, Путчараны мәчет манаралары нурландыра. Аларның күбесе Звенигово районына керә. Быел Йошкар-Олада 80 кв. метрлы бинада мөселман үзәге дә ачылган. Анда биш вакыт азан әйтелә, җомга һәм бәйрәм намазлары күп халык катнашында үтә. Бәрәңге бистәсендә заманның иң авыр чорларында – йөрәкләргә өн салган, гаепсезгә гомерләрне кискән репрессияләр вакытында, Бөек Ватан сугышы барган елларда – 1950 елга кадәр Мәскәүнең Җәмигъ мәчете имамы булган Хәлилрахман хәзрәт Насретдиновның муллалык эшен аның этисе Фидай-Мөхәммәднең бертуган энесе Зөлкарнәйн дәвам иткән. Хәзер аның оныкчыгы Рамил хәзрәт Зөлкарнәев бистәдә дини тормышны җитәкләп бара. Ул Бәрәңге шәһәр тибындагы бистәнең Кызыл мәчетендә (бистәдә ике мәчет бар) имам-хатыйб, җирле дини мөселман

оешмасы рәисе. Рамил хәзрәт Зөлкарнәй мәчеттә дини укулар алып барылуы, анда балалар да, хатын-кызларыбыз да, ир-атлар да укуы турында сөйләде.

Рамил хәзрәт үзенең дәрәҗәле нәселе турында этисеннән ишетеп үскән. Әтисе дә иске татар язуында китаплар укый, яза торган була. Рамил дә кульязмалар белән әтисеннән сорап таныша. Ул үзенең дингә кереп китүен исә Казанга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга баруы белән бәйли. Зөлкарнәйн хәзрәтнең нәсел дәвамчылары Мари Элдә дә, Арча районында да бар. Зөлкарнәйн бабай белән бертуган Гаязетдин Хафизетдин балалары Бәрәңгедә яши. Шуларның берсе Рәйхана Гаязованың тарихчы Фирзия Сабирҗанова белән бергәләп язган «Нәсел хәтирәсе» дигән китабы да дөнья күргән...

Хафизетдин ибн Насретдин әл-Бәрәңгәвинең нәсел дәвамчысы Юшагъ хәзрәт турында Әтнә районынының Күнәр авылы имамы, «Күнәр мәчете нуры» дигән китап авторы Мәхмүт Хәкимҗанов бәян итте. Хафизетдиннең Юшагъ исемле улы Бәрәңге карьясендә дөньяга килә. Ул башлангыч белемне этисеннән ала, гарәп һәм фарсы теленнәге китапларны укырга өйрәнә. 1890 елда аның өченче мәхәллә мәчетендә мәәзин буларак берникадәр яңалыклар кертүе дә теркәлеп калган. Шушы ук елда ул Күнәр авылына килгән һәм 1962 елга кадәр 72 ел дәвамында авылда муллалык вазыйфасын башкарган. Ул таза-сау, зур гәүдәле, ап-ак көрәк сакаллы, мәһабәт кеше була. Хәзрәт яшьлегендә Мари Элнең Путчара авылыннан Маһиҗамал исемле кыз белән никахлаша һәм аны Күнәргә алып кайткан. Шушы вакыйгадан соң ул зиратка бер чыршы һәм нарат агачы утырта. Чыршыны көчле давыл аудара, хәзрәт тормышында да шундый хәл килеп чыккан, абыстай озак яшәмәгән, авырып вафат булган. Хәзрәт хатынлыкка Маһиҗамалның сеңелесе Мәймүнә абыстайны алып кайта. Юшагъ хәзрәт Күнәрнең югары очындагы мәчетендә имам хатыйп булып тора, кышкы айларда җәмәгате Мәймүнә белән бергәләп ир һәм кыз балаларны укырга өйрәтә, аларга дин дәресләре бирә. Юшагетдин хәзрәт ике тапкыр хаҗга барып кайткан. Күнәр халкы хәзрәт белән абыстайны бик ихтирам иткән. Нарат агачына килгәндә исә, ул әле дә исән икән. 98 яшькә җитеп гүр иясе булган Юшагъ хәзрәтнең кабере үзе утырткан нарат агачы янында...

Бәрәңге бистәсенең Кызыл мәчетенең имам-хатыйбы Рамил хәзрәт Зөлкарнәй Хафизетдин ибн Насретдин әл-Бәрәңгәвинең тагын бер дәвамчысы Әхмәт бине Хафизетдинның тормышы белән таныштырды. Ул 1877 елда Бәрәңге авылында Хафизетдин хәзрәтнең гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Башлангыч белемне әтисе Хафизетдин хәзрәттән ала. Әхмәт 11 яшендә Күнәргә кунакка бара, шунда аңарда Бохарага барып уку теләге туа. Әмма 1898 елда аны гаскәри хезмәткә чакыралар. Аннан кайткач, Әхмәт Казанда «Касыймия» мәдрәсәсенә укырга керә, анда дүрт ел белем ала, аннан соң аның Кушлавычта хәлфә һәм имам-хатыйб та булып тора. Ниһаять, егет 1901 нче елда Бохарага юлга кузгала, биш ел дәвамында белем туплап кайткач, Уфада имам-хатыйблыкка имтихан тота. Хәзрәтне Бәрәңгенең дүртенче мәхәлләсенә мөдәррис һәм имам-хатыйб итеп билгелиләр. Ул Әхмәтҗан бай бине Галләм әл Габидиның Өммегөлсем исемле кызы белән никахлаша. 1917 елның апрелендә Өрҗем мөселманнары Әхмәт бин Хафизетдинне Мәскәүгә гомуми мөселманнар корылтаена делегат итеп сайлыйлар. Әхмәт бине Хафизетдин, үз шәҗәрәсен барлап, үзенең туганлык җепләре турында истәлекләр язып калдырган. Аның 223 битлек кулдан язылган «Тарихе Бәрәңгеви» әсәре Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар ядкәрләр бүлегендә саклана. Әхмәт Хафизетдин Р.Фәхреддин кебек олуг галимнәр, дин белгечләре белән элемтәдә булган. Р.Фәхреддиннең аңа язган хатларында Әхмәт хәзрәтнең китабын бик югары бәяли: «Бәрәңге тарихы» гаять гүзәл бер шәйдер, күрер өчен һәм дә истифар кыйлыр өчен (файдалану өчен) зия дә морак итдем (тирәнтен уйландым)», – дип яза. Әхмәт хәзрәт 1924 елда бакыйлыкка күчә. Аның кызы Маһирә Арча районының Апаз авылында улы Илгиз гаиләсендә яшәгән. Аның дүрт оныгы булуы мәгълүм...

Бәрәңгегә килгәч, күп кенә мариларның саф татар телендә сөйләшүләренә игътибар иткән идек. Охшаш сүзләр дә күп икән. Әйтик, кибет кевыт булуын да күреп алдым. Шуңа да тарих фәннәре кандидаты, Мари тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының әйдәп баручы хезмәткәре Тамара Молотованың «Мариларның тарихи-мәдәни традицияләрендә Ислам» дигән чыгышы аеруча кызыклы тоелды.

Казан ханлыгы чорында Идел буенда яшәүче мөселман булмаган халыклар арасында да ислам мәдәниятенең кайбер элементлары тарала, алар гаилә-көнкүреш, җирләү, мәрхүмнәрне искә алу йолаларында, җомга көнен хөрмәтләү кебек гореф-гадәтләрдә чагылыш таба. Гомумән, марилар ислам дине белән Идел Болгары заманында ук танышкан, аларның рухи дөньясын – җәннәт һәм җәһәннәм, язмыш, яшәү мәгънәсе, кешенең дөньяга килү максатлары турындагы уй-фикерләрен тагын да баеткан. Ислам йогынтысында болын һәм көнчыгыш мариларының мәҗүси догаларында ислам дине белән бәйле «бисмилла» («Ысмылла») яки «Алла сакласын» кебек сүзләр барлыкка килә. XVI гасырда мариларның бер өлеше, татарлар йогынтысында, ислам динен кабул итә. 1737 елда Уржум өязендә яшәүче Симей исемле мари алпавытының ислам диненә күчүе рәсми теркәлгән.

Этнограф һәм тарихчы Н.В.Никольский әйтүенчә, марилар, русларга караганда, татарларга күбрәк ышанган һәм алар белән дустанә мөнәсәбәттә булган. Каты чирләп киткән марилар татар мулласына ярдәм сорап килгән. Казан, Мамадыш, Бөре һәм Көнгер өязләрендә яшәүче марилар татарлар белән шулкадәр якынайган ки, алар арасында аерма юкка чыккан диярлек. Төрки халыклар көнчыгыш мариларының рухи мәдәниятенә, аларның бәйрәмнәренә, халык иҗатына да зур йогынты ясаган. Мәсәлән, кайбер мари авылларында Сабан туе һәм Җыен бәйрәмнәре уздырылган. Моннан тыш, көнчыгыш мариларының дога текстлары да ислам дине терминнарына бай булган: алал (хәләл), амен (амин), кавыл (кабул булсын) һ.б. Гыйбадәт кылган вакытта да марилар, мөселманнар кебек үк, тәннең чисталыгына игътибар иткән. Изге аланнарда тәмәке тарту һәм русча сөйләшү дә тыелган. Моннан тыш Т.Молотова 1788-1917 еллардагы Оренбург диния нәзарәтенең архив материалларында мәҗүси мариларның ислам диненә күчерүне сорап язган документлары да саклануын әйтте. Марилар ислам динен кабул иткән очракта исемнәрен генә үзгәртеп калмаган, ә татар яки башкортка, алай гына да түгел, тәкъва мөселманнарга әйләнгән, алар үзләренең кардәшләрен дә ислам диненә өндәгән.

Ислам дине белгече Яков XX гасыр башында Чар өязенең көнчыгыш өлешендә, Казан, Мамадыш, Уфа, Бөре, Минзәлә һәм Малмыж өязләрендә яшәүче марилар татарларның йогынтысына дучар булуын билгеләп үтә. Ул шулай ук Казан өязенең Шурабаш авылында да шундый ук хәл күзәтелгән. Анда яшәүче марилар тәмам татарлашкан һәм аларның шактый өлеше ислам динен кабул иткән. Әмма көнчыгыш мариларының тышкы кыяфәте һәм татар телен яхшы белүләре аларның мөселман икәнлеге турында сөйләми. Мәсәлән, хәзерге көндә Башкортстанның Дүртөйле районындагы Чарлак авылында яшәүчеләрнең күбесен марилар тәшкил итә. «Мариларның татарча сөйләшүенә катнаш никахлар да сәбәпче», – ди Т.Молотова.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

● Сәлимжан Гамиров.

Гадилеккә мәхәббәт белән

Кайсы гына төбәккә барып төшсәк тә, андагы Туган якны өйрәнү музеен карап чыгарга тырышам. Чирмешәнгә баргач та музейны урап үтмәдем. Менә шунда мин агачтан гаҗәеп осталык белән ясалган искиткеч эшләнмәләрне күреп алдым. Юк, оста ниндидер әкияти каһарманнары белән шаккаттырмады, киресенчә, ул безне урап алган гап-гади әйберләрне ясаган, дөресрәге, шул әйберләр дөньясының кечерәйтелгән күчермәсен тудырган. Бу дөнья безгә шулхәтле якын, таныш та һәм шул ук вакытта ул чынбарлыктагыдан камилрәк тә килеп чыккан кебек. Чып-чын авыл йорты, мунча, читән коймалар, ат арбасы, сбруйлары… Әнә капка төбендә күрше Мирсәет абзыйның йөк машинасы тора.Комбайн Минсалих абыйныкы, бик күңелле кеше иде, бөтен урам малаен комбайнына утыртып йөртә иде… Җил тегермәне исә хыял дөньясыннан күчкән кебек. Бу авыл узбаларыннан, останың сизгер бармаклары тудырган микродөньядан чын агач исе бөркелеп тора. Агач исе генә түгел, ә ниндидер яктылык, җылылык, мәхәббәт бөркелә алардан. Ата-бабаларыбыз алып барган тормыш рәвешенә, җиргә, авылга, аның гади матурлыгына мәхәббәт…

Гади агачтан бу мәхәббәтле дөньяны иҗат иткән кеше – Сәлимжан Гамиров булып чыкты. Чирмешән егете, музейда рәссам булып эшли. Авыл җирендә рәсем ясап кына тормыш алып булмый, шуңа да кулы барлык эшне дә белә: кирәксә, эретеп ябыштыра, балта эшен дә коеп куя. Ә агачтан бәләкәй эшләнмәләр ясавы – җан рәхәте өчен. Агачтан мылтык юнып ясап карамаган авыл малае юктыр ул. Сәлимҗан да мылтык ясарга дип әтисенең яхшы такталарын бер генә бозмый, шуның өчен эләккәли дә. Алабуга мәдәният агарту училищесында укып кайткач, осталык тагын да арта. Тема эзләп йөргәне юк – тирә-якка күңел күзе белән карасаң, шул җитә. Юкә, каен, тал агачы – кул астында гына. Киптереп куясың да, җай чыкканда ясыйсың.

Сәлимҗан оста үзендәге һәвәслеккә балаларны да өйрәтә. Башта балта-пычкы тотарга, эш кораллары белән эш итәргә өйрәнергә теләгән дистәләп малай атнага ике тапкыр район үзәгендәге музейга җыела. Тик андагы урынның кысанлыгын, балаларга шартлар җитәрлек булмавын үзе килеп күргәч, хакимият башлыклары Рамил Әйбәтов «Яшьтәш» яшьләр үзәгенә күчәргә тәкъдим итә, анда иркен бүлмәгә тиенәләр. Сәлимҗан абыйлары малайларны өтергә, кул пычкысы, балта тотарга гына өйрәтеп калмый, ә гади әйберләрдә дә матурлыкны күрергә, шуны тотып алырга, үз ачышларыннан сөенергә дә өйрәтә ләбаса. Бармаклар киселеп киткән чаклары да була, тик бу гына ташбашлар күңелендәге дәртне сүндерә ала мыни? Сәлимжан абыйлары әйтүенчә, балалар эш кораллары белән агачтан ниндидер матур әйберләр ясаганда бигрәк тә сабырлыкка өйрәнәләр икән. Остаз Сәлимҗан интернет дөньясына чумган балаларны чынбарлыкка тартып чыгарып, бу дөньяда үз кулларың белән матурлык тудырып булуын күрсәткән, күңелләрен баеткан.

Эльмира СИРАҖИ.

Айга карап кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

2 декабрь (шимбә). ***Җөмәдел әүвәл аеның 19 нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 19.12 сәгатьтә калка, 12.53 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 7.26 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Суган ширбәте

500 г суганны вак кына турап, 1 литр суга салалар, 400 г шикәр өстәп, сүрән утта 2 сәгать пешерәләр. Суытып, 50 г бал кушалар, шешәгә тутыралар. Ютәлне басу өчен, ашаганнан соң, көненә 4-6 аш кашыгы кабалар. Яки кичтән бер баш суганны вак кына турыйлар да, өстенә 2 аш кашыгы шикәр сибәләр. Иртән дару әзер. Көн буена суганын ашыйлар, суын эчәләр. Берничә көннән соң ютәл басыла.

3 декабрь (якшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 21.52 сәгатьтә калка, 13.23 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 7.24 сәгать.***

Теләсә нинди эш башлау өчен айның иң уңай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыңгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Бавыр авыртканда

Бавыр күзәнәкләрен яңарту өчен, көненә 4-5 тапкыр, ашарга 20 минут кала, 1әр чәй кашыгы төелгән шайтан таягы (расторопша) орлыгын кабарга кирәк. Дәва курсы 1 айдан кимрәк, 2 айдан артыграк булмаска тиеш. Яисә 1 аш кашыгы сары мәтрүшкә үләнен 1 стакан кайнар суда 15-20 минут төнәтәләр, үлән төпкә төшкәч, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашаганчы, яртышар стакан эчәләр.

4 декабрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 23.10 сәгатьтә калка, 13.36 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.21 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Грипптан соң

Грипптан соң хәлсезләнгән организмны ныгыту өчен, эмальләнгән кәстрүлгә 1 әр аш кашыгы бал, какао порошогы, атланмай салып, кайнар сулы зуррак савытка утырталар һәм болгата-болгата эретәләр. Көненә 4 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр чәй кашыгы кабалар.

5 декабрь (сишәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 22 нче көне. 22 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Кыз йолдызлыгында, 0.26 сәгатьтә калка, 13.37 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 7.19 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Куркум сихәте

Бронхиаль астмадан интеккәндә, 1 чәй кашыгы куркум порошогын 1 стакан кайнар сөттә эретеп, ач карынга көненә 2-3 тапкыр эчәләр. Бронхит вакытында ютәл җанга тисә, ярты чәй кашыгы куркумны тәлинкәдә яндырып, төтенен иснилэр, бу какырыкны сыегайта һәм сулыш алуны җиңеләйтә.

6 декабрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 1.41 сәгатьтә калка, 13.41 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.17 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Салкын тигәндә

Иртән 2 канәфер бөресен (әлеге тәмләткеч – канәфер агачы чәчәгенең ачылмаган бөресе ул) төеп, бер чәй кашыгы балга кушалар да, кәнфит кебек суыралар. Төшке аш алдыннан кабатлыйлар. Болай дәвалану авыз куышлыгындагы патоген микрофлораны зарарсызландыра. Ютәл интектергәндә, 2 канәфер бөресен 150 мл кайнар суда 10 минут төнәтәләр. Җылытып, вак йотымлап эчәләр. Канәфер "чәе" какырык бүленеп чыгуны җиңеләйтә, карлыгуны бетерә, температураны һәм югары кан басымын төшерә.

7 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 2.58 сәгатьтә калка, 13.46 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.15 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Ангинадан – канәфер

5 канәфер бөресен төеп, 1 стакан кайнар сөткә салалар да, бераз суыткач, һәр йотымны озаклап авызда тотып, эчеп бетерәләр. Яисә 10 данә канәферне 250 мл кайнар суга салып, төнәтәләр һәм шуның белән көненә 4 тапкыр авызны чайкыйлар. Зарарлы бактерияләрне юк итү өчен, 1 канәфер бөресен кәнфит кебек суырырга кирәк, бүленеп чыккан селәгәйне йота баралар, туйдыргач, канәферне чәйнәп йоталар – ул эчтәге суалчаннарны да үтерә.

8 декабрь (җомга). ***Җөмәдел әүвәл аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 13.49 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 7.13 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Кабаклы коймак

300 г чистартылган кабак, 1 стакан кефир, 2 йомырка, 5 аш кашыгы он, ярты стакан шикәр, бер чеметем ванилин, үсемлек мае кирәк. Кабакны уртача угычтан уалар. Җылы кефирга шикәр һәм ванилин салып болгаталар, аннары он кушып туглыйлар. Йомырка сыталар, кабакны өстәп болгаталар һәм табада кыздыралар. Табынга каймак белән бирәләр.

Йолалар –

Быел Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы игълан ителгән иде. Туган төбәгем Чүпрәледә дә күп йола, гореф-гадәтләр әлегәчә зур абруйга ия. Хәзерге заманда йолалар татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә бер-берсеннән аз аерыла. Сүз үткән гасырның 50-60 нче еллары турында барачак, ә ул чорда аерымлыклар шактый күзәтелгән. Сүзебезне кешенең дөньяга килүеннән башлыйк.

Бала туу, исем кушу.

Ул вакытларда хатын-кызлар инде, тулаем алганда, больницада бәбилиләр иде. Ләкин гадәтләр элеккегечә сакланды. Яшь ананы һәм яңа туган баланы өйгә алып кайтканның икенче көнендә бәби (бәбәй – җәя эчендә атаманың мишәр сөйләшендәге варианты бирелә) мунчасы ягыла. Мунчада элек туган-тумача юынып чыга, иң соңыннан, мунчаның кызуы беткәч, бала белән әнисен алып баралар. Элек хатын-кызга мунчага ялгыз барырга рөхсәт ителмәде, чөнки, имеш, шайтан «бәйләнергә» мөмкин.

Бу көн бәйрәм көн булып санала һәм өстәлгә төрле-төрле тәмле ризыклар куела, килгән кешеләрнең барысы да алар белән сыйлана. Кунаклар үзләре дә бүләкләр, күчтәнәч ризыклар алып килә.

Гадәттә, шул ук көнне балага исем (ат) кушыла. Мулла яисә бүтән мәчет карты махсус дога укый, әти-әниләре шуның өчен сәдака бирә. Ул елларда балага исем кушкан көнне өстәлгә эчемлек куелмады. Дөрес, кайбер гаиләләрдә соңрак, «бәбәй туе» булган көнне куелды. Бу вакыйгада инде туганнар, якыннар, дус-ишләр җыелып бәйрәм итә, җырлар җырлана, мәзәкләр сөйләнә, бәби хөрмәтенә бүләкләр тапшырыла, бу «бәбине котлау» дип атала. Бүләкләр кунакларның матди хәленнән тора.

Өйләнү, никах, туй.

Бала үсә, укый, мәктәпне тәмамлый, аннары инде гаилә тормышы турында да уйларга вакыт җитә. Өйләнешү кеше гомерендә була торган иң истәлекле вакыйгаларның берсе. Ул Чүпрәле якларында, күбесенчә, ике төрле була иде: ике якның да әти-әниләре үзара килешеп яки әти-әнигә белгертми яшьләр үзара гына сөйләшеп кавышу. Дөрес, икенче очракның сирәгрәк булуын искәртергә кирәк. Кыз урлау инде ул төбәктә беткән дәрәҗәдә диярлек иде.

Беренче очракта иң элек башкода җибәрелә. Ул авылның тәҗрибәле, утны-суны кичкән карчыгы, сирәк очракларда ир-ат та булуы мөмкин. Башкода ир-ат булса, ул кыз йортына кергәндә чалбарының бер балагын читек өстенә (аяк киеме өстенә) чыгарып керә. Оста телле башкода кияүне, аның әти-әнисен, туган-тумачасын мактый, кызның әти-әниләрен ризалаштырырга тырыша. Соңрак башкода урынына әти-әниләр үзара очрашып кына сөйләшә башлады. Уртак килешүгә ирешелсә, булачак туй мәшәкатьләре, һәр яктан туйга нинди һәм күпме кунак килү, аларның кайсына нинди бүләк бирү, «картлар» һәм «яшьләр» туйларын кайчан һәм кайда үткәрү турында сөйләшү алып барыла.

Икенче очракта кызның әти-әниләренә егетнең берәр олы яшьтәге туганы, әти-әнисе яки әби-бабасы иртәнге якта булган хәл турында хәбәр итәргә килә һәм аларның хәер-фатихасын сорыйлар. Билгеле, бу очракта кызның туганнарына ризалашудан башка урын калмый.

Совет чорында ачыктан-ачык никах укыту яшьләрнең үзләренә дә, әти-әниләренә дә күңелсезлек китерергә мөмкин иде. Шуңа күрә дә никах күбесенчә яшьләрдән башка укыла, ә аларга дога укып «өшкерелгән» ашамлыклардан авыз итәргә генә кушалар иде. Никах укытылмаган туйлар ул вакытларда да бик сирәк булды.

Беренче кич яшьләр кунган йорттан олылар йокларга күршеләргә яки туганнарга китә. Яшьләр өйдә үзләре генә кала. Икенче көн иртән «кияү мунчасы» ягыла. Беренче булып анда кияү белән кәләш юына. Аларның мунчадан кайтуларына коймак пешерелә. Котларга килүче туган-тумача, дуслар белән чәй, соңгы вакытларда «мәй» дә эчелә башлады. Гадәттә, берәр шаянрак дус кеше кияүләрдән: «Мунчаның эссесе (парысы) булдымы соң?» – дип сорап та куя. Загска барып теркәлүләр берничә көннән яки күпмедер вакытлардан соң гына үткәрелә һәм шаһитларның булуы да шарт түгел иде.

Кыз бүтән авылдан булса, аны кияү егете озата бара. Миңа атка матур чана җигеп, чанага юрган-мендәрләр куеп, күршебез Наҗия апа белән иптәше Ахат абыйны Иске Чокалы авылына озата барырга туры килде. Шуның өчен миңа истәлеккә чиккән кулъяулык бирделәр.

Туй мәҗлесләре берничә көннән, атнадан, хәтта айдан соң да үткәрелергә мөмкин. Бу мәсьәләдә гаиләләрнең матди хәле төп рольне уйный, бигрәк тә яшьләрнең әти-әниләре алдан сөйләшеп куелмаса. Кайсыбер вакытларда туй мәҗлесе үткәрешергә яшьләрнең туган-тумачалары да кушыла.

Иң элек олылар – «картлар» туе үткәрелә. «Картлар» туе дип шуның өчен ассызыклап әйтәбез, чөнки туйга, тулаем алганда, олы яшьтәге кешеләр генә чакырыла һәм исерткеч эчемлекләр куелмый. Анда догалар укыла. Шуның өстенә бу мәҗлес көндез үткәрелә.

Туй элек кыз йортында үтә. Кодалар бүләкләр (савым) алып килә. Савым ул – ашамлыклар: зурлыгы якынча 40 х70 см. булган пирог, аның эченә дөге белән вак йөзем яки повидло салынган була, шулай ук өстенә повидло ягып, баусыман итеп эшләнгән камыр белән шакмаклап паштет кебек бизәлергә мөмкин. Аны подноска куеп алып баралар, кабыргалы кул (сарык түшкәсенең чирек өлеше – алгы ягы, ул бөтен көе пешерелә), бал. Болардан башка кызның туганнарына, шул исәптән бала-чагага да, төрле бүләкләр алып барыла. Алар арасында күлмәк (ир-атка), күлмәклек тукыма (хатын-кызларга), яулык, сөлге, кулъяулык, кызның үзе чиккән әйберләр дә булырга мөмкин. Кунаклар күбрәк булганда, мәҗлескә башта ир-ат, алар киткәч, хатын-кыз җыела.

Билгеле бер вакыттан соң туй егет өендә дә үткәрелә. Биредә дә бүләкләр таратыла, догалар укыла.

Әгәр килен башка авылдан булса, егетнең әти-әнисе һәм берничә якын туганы кыз авылына кунакка баралар, бу «туй төшерү» дип атала. Кодалар шул авылда берничә көн кунак була, чөнки кызның туганнары аларны бер йорттан икенче йортка ашка йөртә. Кунаклар тәүлек эчендә берничә йортта булырга мөмкин. Шул ук күренеш егет авылында да кабатлана. Каршы як кодаларны үзләре кыз авылында кунакта булучы туганнар, һичшиксез, кунак итәргә тиеш.

Туйның икенче өлеше исерткеч эчемлекләр белән үткәрелә. Гадәттә ул кияү йортында уза, ләкин, гаиләләрнең матди хәленә карап яки үзара килешү буенча, кыз йортында да үтәргә мөмкин. Бу очракта егетнең әти-әнисе туй үткәрергә булдыра алган кадәр өлешен кертә.

Туй, туган-тумачаның, дус-ишләрнең санына карап, ике, өч көн уздырыла. Беренче көнне парлылар, ягъни ирле-хатынлы кунаклар җыела. Алар башлыча туган-тумачалар, якын күршеләр, дуслар һәм егет яки кызның әти-әниләре, алар эшли торган җирдән дәрәҗәле кешеләр булырга мөмкин. Гадәттә, ирләр бер тирәдә, «түр башы» дип аталган җирдә, ә хатын-кызлар икенче якта яки өстәлнең икенче башында утыра.

Танышлардан яки туганнардан кем дә булса тамада ролен башкара. Ул сүз остасы, туйдагы кунакларны яхшы белүче булырга тиеш. Тамада кунакларга алар соравы буенча сүз бирә, шаян мәзәкләр сөйләп җибәрә. Туйда һичшиксез гармунчы була, ул тальян гармунда яисә хромкада уйнап кунакларны җырлата. Җырлар, күбесенчә, «Урам көе», «Баламышкин», «Алмагачлары» кебек җиңел көйләргә җырлана. Шулай ук авылда киң таралган бүтән җырлар башкарыла. Мәҗлеснең ахырына таба гармунчы уйнаган көй белән җырлаучыларныкы тәңгәл килмәскә дә мөмкин.

Бәйрәм тәмамланыр алдыннан поднослар чыгарыла һәм кунаклар яшьләрне тәбрикләп алып килгән бүләкләрен – кемдер акча, кемдер әйбер куя. Акча ул вакытларда конверт эчендә түгел, ә һәркем күрерлек итеп куелды. Зуррак сумма булса, бүләк бирүче бүтәннәрнең игътибарын үзенә җәлеп итәргә тырыша. Бүләкләрне яшьләр җырлап алырга тиеш, үзләрендә мондый осталык булмаса, туганнарыннан кемдер булыша. Җыр бер яки берничә куплет итеп башкарыла. Мисал өчен түбәндәге җырны китереп үтик:

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме лә Вәлиәхмәт,
Безне болай зурлаганга
Сезгә бездән зур рәхмәт.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, ул чакта кияү белән кәләш хәзерге кебек өстәл башында түгел, ә бөтенләй өстәл артына да утырмый иде. Бөтен мәҗлес дәвамында алар аяк өстендә була, кунакларга сый-хөрмәт күрсәтә, алар сөйләгәнне итагать белән тыңлап тора. Туй барышында аларга ашау түгел, хәтта, кайбер очракларда, су йотарга да мөмкинлек булмый.

Туйның икенче яки өченче көнендә егет һәм кызлар, яшьләрнең дус-ишләре җыела. Бу көнне яшьләргә дә өстәл артына утыру мөмкинлеге туа. Яшьләр туенда кунакларның башкару сәләте көчлерәк була, заман җырлары күбрәк җырланыла. Туйда бары ялгыз биюләр генә башкарыла, хәзерге кебек күп кеше берьюлы бию булмый иде. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, ул вакытлардагы туйларда «Шампанское» шәрабы күбекләнеп агу түгел, бөтенләй булмый иде диярлек, шулай ук «Горько!» дип кычкыру да ишетелмәде, үбешү дә күренмәде. Шуңа да карамастан, гаиләләр ныклы булды, аерылышулар сирәк күренде.

Ул заманнарда туй үткәрү бик мәшәкатьле эш иде. Иң элек тирә-күршеләрдән савыт-саба, өстәл, урындык яки сәкеләр алып торырга туры килде. Электр уты булмаганга күрә, керосин лампаларын әзерлиләр. Аларны шулай ук тирә-күршеләрдән җыештыралар. Бигрәк тә «унлы» лампа булса өй эче яхшырак яктыртыла. Соңрак электр лампочкалары күренә башласа да, ут сәгать төнге 10-11 ләргә кадәр генә бирелгәнгә, хуҗалар станциянең хезмәткәре янына барып, аның җаен җайларга тиеш, шуннан соң

халык мирасы...

инде ут бирү вакыты берничә сәгатькә озайтыла.

Шуны да ассызыкларга кирәк, барлык йортларда да туйлар өстәл артында үтмәде. Шуңа да кунаклар идәнгә, аякларын бөкләп, тезелешеп утырды. Билгеле, хәзерге заманда моны күз алдына китерергә дә авыр.

Ул вакытта өстәлләр дә хәзерге кебек мул ризыктан сыгылып тормады. Менә ул заманнардагы якынча меню: бавырсак, кош теле (зәймә), калач, казанда майда пешкән кабартма, клиндер, прәннек, печенье, пирог, балык консервлары, тозлаган балык, май, корт, каймаклы катык, бәрәңге, ит, аш (ләкшә), сирәк очракларда тозлаган кыяр яки кәбестә, винегрет (шулай ук сирәк йортта), кыш көне булса – холодец (койка).

Иң элек табынга чәй бирелә, ул гадәттә күпләп эчелә, шуңа күрә тирә-күршеләрдән берничә самовар алып килеп куялар. Аш иң соңыннан чыгарыла, бу инде мәҗлеснең ахырга якынлашып килү билгесе дә була. Аштан соң, өстенә ит кисәкләре куелып, берничә тәлинкә белән бәрәңге чыгарыла. Һәр кунак үз кашыгы белән шул ризыкны алып ашый, аерым тәлинкә бирелмәде. Шуннан кунакларның бер өлеше таралыша башлый, туган-тумача, якыннар тагын бераз вакытка калып, бәйрәм барышында бер тамчы ризык та капмаган хуҗалар белән чәй эчәләр.

Мәет күмү.

Кеше туа, үсә һәм якты дөньядан китәргә дә мәҗбүр була. Мәетне күмү Чүпрәле якларында да ислам кануннары белән үткәрелә, бу хәтта совет чорында да шулай булды (кайбер искәрмәләрне санамаганда).

Кеше төнлә яки иртәнге якта вафат булган очракта аны шул көнне үк күмәләр, ә инде көннең икенче яртысында булса, күмү икенче көнгә калдырыла. Бары тик читтән кайтасы туганнары булса гына, мәет берничә көн өйдә ятарга мөмкин.

Мәетне такта яки бүтән каты әйбер өстенә салалар, югыйсә ул бөкерәеп катарга мөмкин, ияген, авызы ачылмасын өчен, яулык белән тарттырып бәйлиләр, ә корсак өстенә кайчы куела. Өйдәге көзгеләр, мәет хатын-кыз булганда, тәрәзәләр дә томалана. Төнлә һәм көндез мәет янында кешеләр булырга тиеш, бу «төнәтү» дип атала. Гадәттә, төн утыручы аерым әбиләр була. Алар дини китаплар укый, пәйгамбәрләр тормышында булган гыйбрәтле хәлләр турында сөйли, тәһлил әйтә. Мәет яткан бүлмәне салкын тотарга тырышалар, хәтта аскы якка таз белән кар яки марганцовкалы су куялар.

Кабер казырга шактый кеше күп җыела, бу хәзерге заманда да шулай. Алар, чакырылып түгел, үз теләкләре белән килә. Кабернең озынлыгы үлчәү таягы белән алына, ә ул үз чиратында мәеттән 20-25 см. озынрак булырга тиеш. Кабер урынын зираттагы эшләрне алып баручы кеше күрсәтә. Гадәттә, туган-тумачаны бер тирәгәрәк күмәләр.

Кабер казый башлаганда, мәчет карты, дога укып, җир йомшак булганда, дүрт почмаклап чирәмне дә кисеп, туң булса балта белән чабып ала. Бүтән төбәкләрдә мәетне ләхеткә салалар. Ләхет дип кабернең көньяк өлешендә уеп ясалган җире атала. Чүпрәледә «шалгама» белән күмәләр: кабер бер метр чамасы тирәнлектә казылгач (сары-кызыл туфракка җиткәч), ике янда киртләч җир калдырып, тагын 70-80 см, ягъни «мәет Мәнкир белән Нәнкир (фәрештәләр) сорау алырга килгәндә торып утырырлык», җир казыла, шуны шалгама дип атыйлар. Киртләчләр мәетне гүргә иңдергәндә басып торыр өчен эшләнелә. Хатын-кыз мәетен күмгәндә киртләч бер якта гына (төньякта) калдырыла, чөнки гүргә иңдерүче ир-ат хатын-кыз мәетенең өстендә аягын аерып басып торырга тиеш түгел.

Шалгама эченә һәр ике якка өчәр имән багана утыртыла, аларга аркылы агачлар (пираклат) куела, шулар өстенә калын нарат такталары җәелә. Шулай эшләгәч кабер беркайчан да ишелми диярлек. Кабер казыганда, берничә балта тота белүче кеше шушы агачларны һәм такталарны эшкәртеп, әзерләп куя. Кабер казылып беткәч, аны сакларга бер кеше калдырыла, калганнары җеназа алырга китәләр.

Шалгаманы казыр өчен «цалыр» дигән махсус җайланма кулланыла. Ул, зур өтерге рәвешле итеп, тимердән эшләнә, кул белән тотар өчен ярымдугага охшаган тоткы беркетелә. Аңа ике тармаклы агач сап куела. Дүрт-биш кеше цалырны күтәреп көч белән җиргә бәрәләр, ә аста берәү тезләнгән килеш тоткадан цалырның очын кирәк урынга юнәлтә барып, җирне каертып ала. Цалыр белән эш итәр өчен, аның остасы булырга кирәк, югыйсә тез капкачын имгәтү очраклары да булгалый.

Кабернең әзер икәнлеге турындагы хәбәрне берәү зираттан кайтып әйткәч, мәетне юалар. Суны махсус коедан дога укып тутыралар, чиләкләрнең өстен томалыйлар һәм коедан кайтканда беркем белән сөйләшмиләр. Чүпрәленең үзендә, мәсәлән, суны Миңналим исемлек карт яшәгән йорттагы коедан алалар иде. Чөнки бу кое сиртмәле, аның өсте һәрвакыт ябык була, суны аннан бер чиләк белән генә алалар, шуңа да ул чиста саклана.

Әгәр мәет ир затыннан булса, аны өч кеше юа. Үлек олы гәүдәле булса, ярдәмгә тагын бер-ике туганнары-якыннары керергә мөмкин. Мәетне махсус «кабык» дигән җайланмага салып юалар, ул бераз авыш була, шуңа да су аяк очына таба агып төшә. Суны махсус «сөннәтле» комганнар белән салып торалар. Мондый комган кулдан эшләнгән була, борын очына алка кидерелә, шуңа да ул «сөннәтле комган» дип атала. Мәетне юучылар өчен махсус кулкигечләр, алъяпмалар тегелә. Хәзер моның өчен резинадан эшләнгән махсус медицина кулкигечләре кулланыла. Мәетне башыннан алып аяк очларына кадәр сабынлап, шул исәптән борын, колак тишекләрен дә юалар. Аннары коендырып тәнен махсус (тән киптергече) чүпрәк белән киптерәләр.

Хатын-кызлар алдан ук кәфен әзерләп (печеп) куя. Кәфен 10-12 м. бүз яки марлядан булырга мөмкин. Мәеткә башта ләхет күлмәге кидерелә, кәфенгә төргәч аны баш, бил, аяк турыларыннан бәйләп куялар. Элек, кәфенгә төргәч, мәетне күрсәтү тыела иде. Хәзер баш ягыннан кәфенне бәйләгәнче мәрхүм белән хушлашырга рөхсәт ителә. Бары тик аңа кагылырга, күз яше тамызырга ярамый. Шулай ук кычкырып елау да тыела. Мәетне юучыларга сәдака бирелә. Озатканда мәетне тагын одеялга яки паласка чорныйлар, өйгә ислемай сиптерәләр. Шуннан соң картлар тәһлилгә керә. Догалар укылгач, әйтелгән тәһлилләрне, шул исәптән төнлә белән карчыклар укыган (тарткан) тәһлилләрне дә, тутырылган коръәне булса, аны да, багышлыйлар. Тәһлилдән соң шунда булган кешеләргә мәетнең туганнары акча, сөлге яки кулъяулык, сабын тарата.

Мәетне аягы белән алга таба алып чыгалар һәм җеназага салалар. Җеназа укыла. Элек җеназа укырга картлар гына, хәзер инде шунда катнашучы барлык ир-ат та баса. Җеназа укылганнан соң, мулла вазыйфасын башкаручы: «Җәмәгать, бу кеше яхшы идеме?» – дип сорый. Аңа: «Яхшы иде!» – дип җавап бирәләр. Шуннан соң җеназаны күтәреп зиратка юл алалар. Елның вакытына һәм зиратка кадәр араның ераклыгына карамастан, җеназа кулда һәм кызу алып барыла. Хатын-кыз мәетен алып барганда, җеназа өстенә агач яки тимер чыбыктан дуга куела һәм ул чаршау белән ябыла.

Мәетне гүргә иңдерү өчен кабергә өч кеше, гадәттә икесе туганнарыннан, якыннарыннан, төшә. Аны йөзе белән кыйблага каратып салалар, баш, бил һәм аяк очын бәйләгән бауларны чишәләр. Мәет хатын-кыз булса, аны кабергә күчергәндә һәм шалгаманы такталар белән томалаганчы, кабер өстен чаршау белән каплап торалар. Мәчет картларыннан берәү дога укып җир кисәге бирә, аны мәетнең баш очына куеп калдыралар. Шуннан аркылы агачларны куеп такталарны җәяләр һәм туфракны кабергә төшерә башлыйлар. Берәү такталар урыннарыннан кузгалмасыннар өчен туфрак белән томаланганчы кабердә тора. Элек кызыл (сары) балчык төшерелә. Үлчәү таягы кабергә кадап куеп калдырыла. Туфрак өелеп беткәч, булса, рәшәткә урнаштырыла. Элек кабер өстенә рәшәткә дә, һәйкәл дә куелмый, үлчәү таягы гына куела иде.

Шуннан соң дога укыла. Дога укылып беткәч, зиратта булган барлык кешеләргә сәдака өләшенә. Мәрхүмнең туган-тумачасы күп булганда, сәдаканы ун һәм артыграк кеше өләшергә мөмкин. Сәдаканың күләме һәркемнең матди хәленә карый, бары бер генә шарт бар, ул да булса дога укучыларга күбрәк бирү. Кешеләр таралышкач, кабернең дүрт почмагына дүрт кеше (карт) утырып дога укыйлар. Элек хатын-кызга зиратка керү тыела иде, хәзер моңа бик игътибар итмиләр.

Мәетне алып киткәннән соң, өйне һәм мәет яткан әйберләрне юып, чистартып чыгаралар. Зираттан кайтучылардан берәү, өйгә кереп дога укый.

Мәрхүмне искә алып, күмгәннең өченче, җиденче, кырыгынчы һәм бер ел (елашы) тулган көннәре билгеләп үтелә. Өчесе үтми торып, мәет чыккан өйдә ашарга һәм эчәргә ярамый. Бу көннәрдә йорт хуҗаларын туган-тумачалары, күрше-тирәләре ашка чакыра.

(Дәвамы киләсе санда).

Иршад ГАФАРОВ,
Зәки Нури исемендәге
премия лауреаты.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

1 декабрь – «Игезәк» (Р.Зәйдулла). Артист Рамил Вәҗиевнең юбилей кичәсе.
2 декабрь – 14.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 18.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
3 декабрь – 12.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 17.00 – «Шәрык клубы» комплексында – «Моңлы тарих» дип исемләнгән ретро-концерт. 18.00 – «Рәшә» (Ә.Еники).
6 декабрь – К.В.Иванов исемендәге Чуаш драма театры сәхнәсендә,
7 декабрь – Апас районы мәдәният йортында – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

1 декабрь – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
2 декабрь – «Ай, былбылым!» (Ш.Фәрхетдинов).
3 декабрь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
5 декабрь – «Ай, былбылым!» (Ш.Фәрхетдинов).
6 декабрь – «Ашина» (Р.Зәйдулла).
7 декабрь – Күренекле артистка Исламия Мәхмүтованың 80 еллыгы уңаеннан «Кыр казлары артыннан» дип исемләнгән искә алу концерт-кичәсе.

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

1 декабрь – «Ал җилкәннәр» (А.Грин).
2 декабрь – Туймазы Татар дәүләт драма театрының «Борһан йорты» спектакле.
3 декабрь – 11.00 – «Әлифба» (Л.Әхмәтҗанова, Ф.Насыйбуллин, Э.Яруллина). 18.00 – Әлмәт Татар дәүләт театрының «Дөм» спектакле (Л.Толстой әсәре буенча).
4 декабрь – Әтнә Татар дәүләт драма театрының «Наташаның хыялы» спектакле.
5 декабрь – Ачинск дәүләт драма театрының «Первая любовь» спектакле.
6 декабрь – Сарапул дәүләт драма театрының «Сказка о мертвой царевне» спектакле.
7 декабрь – «Доминанта» камера драма театрының «Тихий свет» спектакле (Р.Козырчиков).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

1 декабрь – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәре буенча). 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
2 декабрь – 15.00 – «Репка-Ряба-Колобок» (Н.Шмитько инсценировкасы).
17.00 – «Камал комедияләре» (Г.Камал).
3 декабрь – Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Муха-цокотуха» (К.Чуковский). Кече залда – «Кәтүкнең сихри төшләре» (И.Нәфиев, Х.Ибраһим).
5 декабрь – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
6 декабрь – С.Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрының «Шулай булды шул» спектакле (Т.Миңнуллин).
7 декабрь – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 декабрь – «Путь героя» беренче иммерсив психологик моно-спектакль.
3 декабрь – Әдәби-музыкаль лекторийның «Ак җилкәннәр» дип исемләнгән концерт программасы. Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Георгий Ибушев, Гөлнара Байназарова, Тимур Сабиров, Оксана Шәйдуллина һ. б. катнаша. Программада – татар композиторлары җырлары һәм романслары.
4 декабрь – Алиса Маминаның «Зорька алая» дип исемләнгән концерты.
5 декабрь – Филармония джаз оркестры һәм Валерий Сюткин концерты.
6 декабрь – «Маяковский – Есенин. Дуэль в стихах» дип исемләнгән шигърият кичәсе.
7 декабрь – Валерий Михальченко исемендәге Чиләбе камера хоры концерты.

Чынга ашкан фараз

1983 елның 30 ноябрендә Үзәк Разведка Идарәсе (ҮРИ – ЦРУ) аналитигы Герберт Мейер яшерен доклад белән чыгыш ясый. Аны нибары ике кеше – ҮРИ директоры Билл Кейси һәм АКШ Президенты Рональд Рейган тыңлый. “Дөнья ни өчен шулкадәр куркыныч?” дип аталган докладында Мейер СССРның тиздән таркалачагын фаразлый, әмма Рейган һәм Кейси моңа ышанмый. Ул чакта барысы да, АКШ һәм СССР әле тагын берничә дистә ел буе бер-берсенә каршылык күрсәтеп яшәячәк, дип инанган була. Америкалылар якындагы 20 елда СССРның Европаны тулысынча үз контроленә алуыннан курка. Әмма Мейер моның киресен исбатлый. “Бүгенге тенденцияләр сакланса, без салкын сугышта җиңәчәкбез”, – ди ул. Аның төп дәлилләре нинди була соң? Советлар Берлеге бербөтен түгел, ул йөздән артык милләтне берләштерә, алар барысы да сәяси һәм икътисади бәйсезлек өчен көрәшә, һәм руслар хакимлеге озак дәвам итә алмаячак. Чыннан да, СССР таркалгач, элекке республикаларның сәяси элитасы теләгәнчә ирешә – үз җирләрендәге бөтен байлыкка хуҗа була, гади халыкка гына бернәрсә дә эләкми. Совет икътисадының үсеш темплары елына уртача 2 процент тәшкил итә, ә хәрби чыгымнар елына 4 процентка үсә, шунлыктан тормышның һаман начарая баруы бер дә гаҗәп түгел. Илдә “демографик афәт” күзәтелә – XX гасырда планетада халык саны 3,5 тапкыр артса, Советлар Берлегендә нибары 18 процентка ишәя: 1979 елда бирелдә барлыгы 262 миллион кеше яши (әгәр демографик вазгыять АКШтагы дәрәҗәгә җитсә, СССРда 600 миллионнан артыграк кеше яшәргә тиеш була). Мейер әйтүенчә, илдәге һәр хатын-кызга алтышар аборт туры килә. Бала туу кимегәч, дәүләт предприятиеләрендә эшчеләр саны да кимеячәк, бу СССР өчен билгеле бер вакыт узгач шартлаячак мина булып тора. Мейер докладын: “Ирекле дөнья Советлар Берлеген икътисади яктан күптән артта калдырды, ә сәяси яктан – таптап изде”, – дип тәмамлый. Аналитикны әлеге докладына өчен тәнкыйтьлиләр, хезмәттәшләре аны акылдан язганга саный, җитәкчеләре шелтәли. Ә инде 8 елдан соң СССР таркалгач, Мейерга Милли разведка хезмәте медален тапшыралар һәм аның докладын, интеллектуаль фаразлауга иң шәп мисал, дип мактыйлар.

(“ИноПресса.ру”).

Карантин өчен идеаль кала

2017 елда Си Цзиньпин фәрманы буенча Пекиннан 100 чакрым ераклыкта салына башлаган Сюнъань шәһәре иң заманча кала булырга тиеш. Әлеге проект белән Коммунистлар партиясе ҮК һәм КХР Дәүләт Советы шөгыльләнү үзе үк аның ил өчен стратегик әһәмияткә ия булуын күрсәтә. 2020 елда карантин вакытында шәһәр проектына шактый үзгәреш кертелә: ул озак вакыт буе үзен-үзе тәэмин итәрлек, бернәрсәгә дә мохтаҗлык кичермәслек кала булырга тиеш. Дүрт кварталдан торган массивта көнбатыш планлаштыруы Кытай шәһәрләренә хас бик биек йортлар белән берләшә. Материалы – инженерлык агачы. Программага гади фатирлар, яшьләр һәм өлкәннәр өчен күмәк торак, офислар, йөзү бассейны, кибетләр, азык-төлек базары, балалар бакчасы, административ үзәк һәм янгын сүндерү бүлеге керә. Беренче катта 3D-принтерлар һәм цифрлы станоклар куелган остаханәләр урнаша, алар халык өчен бөтен кирәкле нәрсәне тиз арада ясап бирә ала. Йорт түбәләрендәге теплица кыекларына кояш батареялары урнаштырыла. Шул рәвешле, комплексларда энергия дә, азык-төлек тә, бөтен кирәкле җиһаз-җайланма да җитештерелә, материаллар һәм суны икенчел файдалану системасы эшли. Фатирлардагы көньякка караган террасалар карантин очрагында урамны алыштырырга тиеш. Ерактан торып эшләү өчен шартлар тудырыла: йортлар 5G челтәренә тоташтырыла, фатирларда кечкенә офислар җайлана. Шәһәр буйлап бары тик пилотсыз транспорт кына йөри.

(“Guallart Architects”).



Сомерсет Моэм.

Жорж Сименон.



Марк Твен.

Марсель Пруст.

Кем ничек яза бит

